А. Г. ЯХИН

Әдәбият

3

Беренче кисәк

А. Г. ЯХИН Әдәбият 3

«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

А. Г. ЯХИН

Әдәбият

Татар телендә
башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең
3 нче сыйныфы өчен дәреслек

Ике кисәктә

Беренче кисәк

*Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан
рөхсәт ителгән*

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2010

УДК 373.167.1:821.512.145*03
ББК 84(2Рос=Тат) я71
Я89

Рәссамнары:

Рәисә Сәйфуллина, Алексей Мамаев

Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Шартлы билгеләр:

?! — сораулар һәм биремнәр;

— иҗади эш;

— мөстәкыйль эш;

— тиз, дөрес, аңлап уку өчен текстлар.

Яхин А. Г.

Я89 Әдәбият : Татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 3 нче с-фы өчен д-лек : Ике кисәктә. Беренче кисәк / А. Г. Яхин.— Казан : Мәгариф, 2010.— 123 б.

ISBN 978-5-7761-2065-7

ISBN 978-5-7761-2065-7

© «Мәгариф» нәшрияты, 2010
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2010

Беренче һәм икенче сыйныфларда өйрәнгәннәрне искә төшерү.

БЕЗНЕҢ ГАИЛӘ.

Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи —
Безнең өйдә без җидәү: безнең песи — җиденчесе.

Бергә ашый, чәй эчә, безнеңлә бергә йоклый ул,
Хезмәте дә бар: өйне тычкан явыздан саклый ул.

Габдулла Тукай.

?! 1. Шигырьдә кешеләр, балалар һәм песи катнаша. Шулай дисәк, дөрес буламы?

2. Анда тычкан да катнашамы?

3. Әсәрне ике өлешкә бүлегез.

БЕЗ НИЧӘҮ?

Әтием бар,
Әнием бар,
Ике апам.
Әниемнең
Әнисен дә
Бик яратам.

Ә без, аның
Оныклары,
Өчәү инде.
Шулай булгач,
Без барыбыз
Ничәү инде?

Хәкимҗан Халиков.

?! Сорауга җавап бирсәк, без дә шигырьдә катнашучы булабыз. Шигырьдән авторны һәм үзегезне табыгыз.

ТӨЗӘТӘМ.

Төзәтергә яратам мин,
Төзәтәм дә төзәтәм.
Яңартам уенчыкларны,
Үзгәртәм дә үзгәртәм.

Тәгәрмәчләр алыштырам.
Алыштырам кузовлар.
Уенчыкны төзәтмәсәң,
Уйнап нинди кызык бар!

Борып куям, кагып куям,
Беләм бөтен җирләрен.
Үзем оста, беләм ничек
Төзәтергә кирәген.

«Ватасың гына бит!» —
диләр,
Ватмагачтын бернине,
Ничек итеп төзәтәсең
Ватылмаган әйберне!

Нурия Измайлова.

?! **1.** Шигырьдән охшаш авазлы сүзләрне табыгыз.

2. Оста малай сезгә кайсы ягы белән ошый, кайсы ягы белән ошамый?

3. Шигырьдә автор безгә нәрсә дип әйтергә тели?

ВАСЫЯТЬ.

Борын заманда булган, ди, бер карт. Үләр алдыннан, карт улын чакырып алып әйткән: «Син, улым, дигән, хәлеңнән килсә, авыл саен йорт сал»,— дигән.

Ярар. Карт үлеп китә. Әтисе үлгәч, улы: «Әти әйткән васыятьне ничек кенә итеп үтәрмен, ничек кенә авыл саен йорт салырмын икән?» — дип баш вата икән.

Көннәрдән бер көнне моның янына бер карт килеп керә. Исәнлек-саулык сораша, тормышы белән кызыксына бу моның.

—Тормыш бик шәптән түгел, бабай,— ди егет.— Әти үлгән вакытта: «Авыл саен йорт сал»,— дип әйтеп киткән иде, әле әтинең васыятен үти алганым юк,— ди.

—Әй улым, син әтиеңнең васыятен ялгыш аңлагансың икән, ди. Ул сиңа менә болай дип әйткән, ди: «Авыл саен йорт сал» дию — авыл саен дус-иш булдыр, дөньяда дуслар белән яшәве җиңелрәк дип әйтүе булган,— ди.

Шулай дип әйтә дә карт чыгып китә. Ә егет әтисенең васыятен...

?! 1. Соңгы җөмләнең ахырын «Ә егет әтисенең васыятен шунда ук үти» дип тәмамласак, дөрес буламы?

2. Ни өчен авыл саен йорт салырга кушу васыяте дус-иш булдыру дигән сүз?

3. Автор безгә нәрсә әйтергә тели?

ЭШ ҺӘМ ЯЛ.

Кайтуы белән дәрестән,
Булатларга керде Рөстәм.
— Әй син! — диде ул аңарга,—
Тиз чыгасыңмы уйнарга? —
Булат төймә тага иде:
— Мин бераздан чыгам,— диде.—
Әле төймә тагасым бар,
Аннан утын ярасым бар.
Рөстәм йөгерде Илдарга,
Чакырды аны уйнарга.
— Әле чыкмыйм, — диде Илдар,—
Минем чана ясыйсым бар.

Чана сорый энем Гали.
Ул, беләсең, үзе нәни! —
Рөстәм керде Әхтәмнәргә,
Аны уенга өндәргә.
Әхтәмнең әнисе әйтте:
— Ул тагын мәктәпкә китте.
Ул һәр шимбә мәктәптә
Эшли физтүгәрәктә!



Гаталарга керсә, Гата
Электрны төзәтеп ята.
— Әле бик тиз чыгалмыйм, ди.
Яктыда эшләп калыйм, — ди.
Сәлимгә керсә, анысы
Кайрап ята зур бер кайчы.
— Тотынганчы дәресләргә,
Кирәк, ди, бераз эшләргә.
Хәзер кисәм мин калай, ди.
Мотор ясыйм мин, малай,— ди.

«Кыз кеше булса да, шунда
Уйнарга ярар, дип, ул да!»
Сараларга керде Рөстәм.
Ә ул кайтуга дәрестән,
Тотынган идән юарга.
— Шунсыз чыкмыйм, ди, уйнарга.—
Шуннан өйдән өйгә йөреп,
Шактый вакытны уздырып,
Рөстәм бик күңелсез генә
Чыкты да капка төбенә,

«Нишләргә?» — дип, башын кашып,
Шактый торды шунда басып.
Рөстәм тәмам аптырады
һәм үз-үзеннән сорады:
— Нишләгән соң бу балалар?
Ял итә соң кайчан алар?
....

Әхмәт Исхак.

?! **1.** Шигырьдә бер-берсенә охшаган алты вакыйга бар. Кушып, барысына бер исем бирегез.

2. Күп нокталар урынында шигырьнең тагын бер строфасы бар. Ул строфасында автор укучыга нәрсә әйтер икән?

3. Әсәрдә авторны табыгыз.

ЯШЬЛӘР КОЛАГЫНА.

Бәйрәм килгән көннәрдә
Сезнең өчен бу яшьләр,
«Әйбәт булам» дигәнгә
Иң кирәкле киңәшләр:

Һәр көненә елмаеп кер,
Елмаю ул күп бирә.
Бер тиенсез бүләк инде —
Тормый бит ул берни дә!

Биргән кеше берни җуймый,
Алган кеше күп ала;
Бер мизгеллек елмаю да
Гомергә истә кала.

Әгәр кеше, гел әйбәт дип,
Сине уйласын дисәң,
Иң элек аның исемен
Хәтереңдә йөрт, иркәм.

Аңа башка исем белән
Эндәшә күрмә тагын,
Һичкем һичкайчан кичермәс
Исемен бутаганын.

Ошатып калсыннар дисәң...
Әңгәмәдәшләр сине,
Оста сөйләү генә җитми,
Оста тыңлый бел инде.

Бәхәсләрдә җиңеп чыгыйм дисәң...
Кача белү кирәк бәхәстән.

Шулай булгач, бәхәс барган төштән
Борыл да кит берни әйтмәстән!

Әңгәмәдәшеңне хөрмәт итсәң,
Беркайчан да аның сүзен бүлмә.
Һәм беркайчан аңа: «Синең сүзең
Дөрес түгел, димә, хаксыз»,— димә.

Үзең хаксыз чакта гафу үтен,
Гаебеңне таны тиз арада.
Бер хатасыз тик бер Алла гына,
Син бит Тәңре түгел, шуны аңла!

Клара Булатова.

?! Авторның безгә биргән матур киңәшләрен үз сүзләрегез белән кыска гына итеп әйтегез.

Җансыз әйберләргә кеше сыйфатлары биргәндә, автор күренеп тормый. Ләкин без аның шунда булуын беләбез. Мәсәлән,

ЯЗ.

Кышкы күктә болытлар
Толып киеп йөргәннәр.
Әйе, шулай йөргәннәр.
Язга шулай кергәннәр.

Толыпларын салырга
Онытканнар да алар —
Инде хәзер тирлиләр,
Тирлиләр дә эриләр,
Яңгыр булып явалар.

Рөстәм Мингалим.

?! Автор болытларны толып кигән кешеләргә охшата. Яңгырлы болыт, чыннан да, толыпка төренгән кеше кебек күперәп тора. Авторның беренче уңышлы табышы шул. Икенче матур табышы турында сөйләгез.

ЯЗ.

«Яз киләдер, яз килә!» — дип, кар эрергә ашыга;
Күп тә үтми, кар бетә, кырлар, болыннар ачыла.

Нәҗип Думави.

?! 1. Шигырьдә автор катнашкан урынны табыгыз.
2. Шигырьне кыскартып, үз сүзләрегез белән әйтегез.

КИЧКЕ КОЯШ.

Күзе кызарган кояшның —
Йокысы килә бугай.
Түшәк җәеп кетә аны
Болында яшел тугай.

Ләкин күкләр улы кояш
Безнең янга төшәрме?!
Алтыннан аның сарае,
Ак болыттан түшәге.

Разил Вәлиев.

?! Шигырьнең эчтәлеген табигать күренеше итеп кенә сөйләгез. Мәсәлән, «Кояш баерга җыена...» дип башлап була. Аннан соң автор катнашында җанланган шигырьне үз сүзләрегез белән сөйләгез.

КЫЗЫК ӘКИЯТ.

Онык. Бабай, берәр кызык әкият сөйлә әле?

Бабай. Көлкеле, дисеңме? Йә, ярый. Сөйлим: ике крокодил, кем кемнең башын кабып өзә, дип бәхәсләшкәннәр. Отучыга оттыручы алма бәлеше бирергә тиеш, дип килешкәннәр. Аңлашылдымы?

Онык. Аңлашылды, бик аңлашылды, бабай.

Бабай. Менә мо-ондый дәү крокодил авызын менә шушылай зур итеп ачкан да һап — кечерәгенең башын кабып өзгән. Кечкенәсе җиргә ауган да: «Ярый, син оттың»,— дигән.

Онык. Башсыз крокодил ул сүзләрне ничек әйтсен, ди?

Бабай. Кызыгы да шунда бу әкиятнең, балакай.

?! Әкиятнең кызыклыгы нәрсәдә?

БӘХЕТ ЧИКЛӘВЕКЛӘРЕ.

Өч бертуган егет, акча эшләргә дип, читкә чыгып китәләр. Юллар аерылган чатка җиткәч, олы абыйлары:

— Мин уңга, тауга менеп китәм, син, уртанчы энем, сулга, ә син, төпчек энем, туры китәрсең. Өч елдан соң нәкъ шушы вакытта, шушы урында очрашырбыз. Кемнең күпме акча эшләвен күрербез,— ди.

Энеләре риза булалар. Саубуллашып, үз юллары белән китәләр.

Өлкән туганнары шәһәрдә кала. Ипи пешерүче булып эшли һәм тиз арада шактый акча төшерә. Уртанчы туган күпер төбендә ашханә ача, һәм ул да

бик тиз байый. Ә кече туган бер карт көтүчегә ярдәмче булып яллана.

Өч ел үткәч, көтүче егеткә хезмәт хакын түли. Өстәлгә бер уч акча өеп куя һәм кесәсеннән өч чикләвек алып күрсәтә дә:

— Мин карт кеше. Сарыклар артыннан чаба алмыйм инде. Синең ярдәмең белән шул өч ел эчендә бер сарыкны да югалтмадым. Рәхмәт сиңа. Хезмәтеңә тигән өлешеңне сайлап ал. Менә акча, менә чикләвекләр. Акчаны изге теләк белән бирмим, чөнки акча ут кебек ул, кулны пешерә. Ә менә чикләвекләрне ихлас күңелдән, изге теләк белән бирәм. Сайла, — ди.

Егет уйлап-уйлап тора да кулын чикләвекләргә суза.

— Чын күңелдән, изге теләк теләп биргәч, чикләвек алам, — ди.

Егет, чикләвекләрен алып, карт көтүчегә рәхмәт әйтеп, кайтыр юлга чыга.

Сүз куешканча, туганнар юл чатында җыелалар.

— Юлыгыз уңышлы булдымы? — дип сорый өлкән агалары.

— Уңышлы булды, — дип җавап бирә кече туган.

— Карап карыйк! Башта минем хезмәт хакына карагыз, — ди өлкән агалары һәм букчасын чишә, уртанчы агалары янчыгын ача.

Кече туганнары кесәсеннән өч чикләвеген чыгарып күрсәтә.

— Өч елда эшләп алган хезмәт хакың шул гынамы? — дип гаҗәпләнә өлкән агалары.

— Шушы өч чикләвек кенә. Ләкин алар — чын күңелдән, изге теләкләр теләп бирелгән чикләвекләр. Миңа аларны яхшы эшләгән өчен карт көтүче бирде.

Ул мине үз улы кебек тәрбияләде, — ди кече туган.

Абыйларының ачуы чыга.

— Тиләләрне моңа кадәр дә күргән бар иде, синдәй ахмакны күргән дә, ишеткән дә булмады. Өч ел эчендә өч чикләвек эшләп алуны кемнең кайчан күргәне бар? Хәзер үк көтүчең янына бар да эшләгәнең өчен тиешле акчаңны сорап ал! Әти янына акчасыз кайтып керәсе булма! — дип кычкыра өлкән абыйлары.

Кече энеләре хәсрәткә бата. Кайткан юлыннан кире китә. Бара-бара, үз-үзе белән сөйләнә:

— Дөньяда чын күңелдән биргән әйбердән дә кыйммәтрәк бернәрсә дә юк, дип уйлый идем. Менә нәрсә килеп чыкты, — ди.

Шулай сөйләнеп бара торгач, чишмә янына килеп җитә. Тамагы ач булганга, чишмә суын аз гына эчә. Букчасын бушатып карый: ник бер бөртек икмәк валчыгы булсын! Чикләвекләремне ватам да ашыйм. Аз булса да тамак ялганыр, дип уйлый егет һәм берсен вата башлый. Ватарга да өлгерми, чикләвек аркылыга-буйга үсәргә тотына. Бик тиз арада йөз чиләкле мичкә хәтле була. Ул да булмый, чикләвек кабыгыннан сарыклар, сарык бәрәннәре, муеннарына кыңгырау таккан тәкәләр чабып чыгалар. Бер чикләвектән чыккан мал бөтен бер көтү була.

Шатлыгыннан нишләргә белми егет. Көтүен куып, өйләренә кайтып китә. Кайта-кайта, туган авылы күренә башлый. «Чикләвекләрнең тагын берсен ватып карыйммы әллә? Анысы эчендә нәрсә ята икән?» — дип уйлый егет.

Икенче чикләвекнең кабыгын яру белән, ярыктан ике озын мөгезле яшь үгез, үгез артыннан сабан салынган арба килеп чыга.

— Менә ичмасам могҗиза! — дип, маңгаена шап итеп суга егет һәм, үгезләрне ияртеп, көтү артыннан китә. Авылга җитәрәк, әченче чикләвеген дә вата. Ватык чикләвек кабыгыннан пәйда булган кыз чибәрлеген күргән кеше, һичшиксез, һуштан язар иде.

— Әтиең янына алып бар. Синең хатының булу язмышка язылган безнең,— ди кыз.

Егет кызны арбага утыртып кузгала. Сарыклар чаба, кыңгыраулар чылтырый. Егет өйләренә кайта да туй ясый.

?! **1.** Әкиятне кызык итә торган вакыйгалар турында сөйләгез.

2. Автор безгә әйтергә теләгән сүзләрен әкиятендәге вакыйгалары эченә яшергән. Ул безгә нәрсә әйтә?

ЮЛ.

—Юл, мин әсәр язам. Әсәремнең төп персонажы булырга риза буласыңмы? — дип сораган бер кыз.

—Әсәреңне кеше укырмы соң? — дип сораган Юл.

—Ул әсәрне белмәүчеләр бик аз булачак,— дип ышандырган кыз.

—Кара аны, мине кире персонаж итеп язасы булма. Югыйсә юлдан яздырырмын,— дигән Юл.

Шактый вакыт үткәч, кыз әсәрен Юлга укып күрсәткән:

«Агачтан озын, үләннән тәбәнәк»,— дип укыган кыз.

—Шул гынамы? — дип сораган Юл.

—Шул гына,— дип җавап биргән кыз.

—Мин юк бит монда? — дип үпкәләгән Юл.

—Бар,— дигән кыз.

?! «Әсәрем кечкенә булса да, анда син дә, әсәрне укучы да, мин дә катнашам. Безнең барыбызны да таба белергә генә кирәк»,— дип аңлаткан кыз. Кыз хаклы. Ул әйткәннәрне исбат итегез.

ЯШЬЛЕК ЧИШМӘСЕ.

Әллә кайчан булган, ди, бу
Борын заманда.
Тора әби белән бабай
Яшел аланда.
Беркөн аудан кайткан чакта,
Күләгә төштә
Бабай күрә тау төбендә
Көмештәй чишмә.

Җиргә ятып шул чишмәдән
Салкын су эчә.
Чү, кинәт күзе судагы
Шәүләгә төшә.
Матур бер егет сурәте
Суда чайкала;
Бабай әйләнсә артына —
Аптырап кала.
Беркем дә юк.
«Күзем ялгыш
Күрәме әллә?»
Ул чишмәгә тагын карый,—
Тагын шул шәүлә.
Ул күзләрен уа башлый,
Шәүлә дә уа,
Ул тезләнә торып шунда,
Шәүлә дә тора...
Бабай аңлап ала эшне,
(Сүлпәнлек кая!)
Хәзер инде ул яшь егет!
Карт иде бая.
Өйгә кайта. Әби аңа:
— Ни йомыш, балам?
Бүген бигрәк озаклады,
Өйдә юк бабаң.—
Егет-бабай көлеп әйтә
Әбигә шунда:
— И карчык, ди, бабаңдыр бу
Синең каршыңда!..
Бер чишмәдән эчкән идем —
Яшәрдем менә!

Кинәт кылт итеп шик төшә
Әби күңеленә:
Өстендәге киемендә
Җиде ямау бар,—
Җидесе дә әби үзе
Салган ямаулар.
Аягында да бик таныш
Иске күн итек...
Чү, бер колак йомшагы да
Әз генә китек.
Ышандыра бит әбине
Барлык билгеләр:
—Йә, ник берсүзсез торасың,
Әйт тизрәк, юләр!
Миңа да өйрәт ул юлны,
Кайда ул чишмә?
Яшь кыз булып синең янга
Кайтырмын кичкә...—
Егет-бабай чишмә юлын
Өйрәтеп бирә.
Менә әби җан-фәрманга
Шунда йөгерә.
Арып-талып барып җитә
Ул тау буена.
Ярга ятып рәхәтләнә
Чишмә суына,—
Туймас кебек кабаланып
Чөмерә башлый...

Нури Арсланов.

?! Әкиятне автор ничек тәмамларга мөмкин? Ахырын уйлап табыгыз.

Әсәрне өлешләргә таркату.

Әсәрнең эчтәлеген анализ ясап беләләр. Анализ әсәрләрне өлешләргә таркатудан башлана. Әсәрне өлешләргә «Ни турында? Тагын ни турында?» сораулары бирә-бирә бүләләр.

Хәтта кып-кыска мәкальләр дә ике өлешкә бүленәләр.

Белгән укыр, белмәгән тукыр мәкаленең өлешләре күренеп тора. Ул, «белә торган кеше турында» һәм «белми торган кеше турында» дип, ике өлешкә бүленә.

«Белгән укыр» өлешенең эчтәлеген болай аңлатабыз:

Укымышлы бала мин беләм дип мактанып йөрми. Күбрәк укыган саен, үзен аз белүче дип саный. Шуңа күрә укый-укый белемен күтәрә.

«Белмәгән тукыр» өлешен болай аңлатабыз:

Белемсез бала берни белмәсә дә сөйли дә сөйли. Башкаларга акыл сата.

?! Рәсемнәрне карагыз. Беренче һәм икенче өлешләрен табыгыз һәм алар арасындагы бәйләнешне күрсәтегез.

ЧИСТАЛЫК ЯРАТАБЫЗ.

Су буенда, ком өстендә
Уйныйбыз төрле уен.
Уйнап туйгач, чүп-чарлардан
Чистартабыз яр буен.

Дулкыннар да чүпне судан
Күтәреп ярга ата.
Димәк, алар да, безнең кук,
Чисталыкны ярата.

Мәрзия Фәйзуллина.

?! **1.** Шигырьне ике өлешкә бүлегез.

2. Ике өлеш бер-берсенә охшаган. Шуңа күрә алар арасында охшашлык бәйләнеше бар, дибез. Шигырьнең икенче өлешендә автор безгә нәрсә әйтә?

ТАШБАКА ИЛӘ КУЯН.

Ташбака илә Куян, узышмакчы булып, бер тауга таба йөгерешә башладылар. Куян, үзенең йөгереклегенә ышанып, юлда ятып йоклады.

Куян, берзаман йокысыннан уянып, алга караса, Ташбака әллә кайчан тауга барып җиткән! Инде безнең Куян артка калганына үкенде дә, хурланды да, әмма ни файда?

* * *

Көчлегә үзендәге көчкә ышанырга ярамый. Кечкенә генә дошманга да зур дошманга әзерләнгән кеби әзерләнергә тиеш.

Габдулла Тукай.

?! 1. Әсәрне ике өлешкә бүлегез.

2. Автор әсәрнең кайсы урынына килеп керә?

3. Мәсәлнең геройлары — Ташбака белән Куян. Автор аларның нинди сыйфатларын күрсәтә?

АК КҮБӘЛӘК.

Урман арасында чәчәкле юл,
Барам карап тирә-ягыма,
Каеннарның яшел яфраклары
Шыбырдашып канат кагына.

Чәчәкләргә карыйм — куаналар,
Баш ияләр миңа — елмаям.
....

Фатих Кәрим.

?! 1. Шигырьне ике өлешкә бүлегез. Авторын табыгыз.
2. Шигырь тәмамланмаган. Ничек тәмамлар идегез?

АЙ.

Минем артымнан калмый
Өйгә хәтле кайтты ай.
Һавада юктыр кызлар,
Һавада юктыр малай
Аның белән уйнарга.
Уенчыкларны ничек
Шунда менгереп куярга?
Песи дә юктыр әле
Бөгәрләнеп йокларга.
Йоп-йомшак юрганда
Караватсыз-песисез
Ничек йоклар ул анда?

Тәрәзәдән ай карый...
Янында балалары —
Йолдызлары бар ярый!

Рәшит Бәшәр.

?! 1. Шигырьдә катнашучылар ничәү?
2. Төп катнашучыларны гына кертеп рәсем ясагыз.
3. Төп герой кем: аймы, песиме, уенчыклармы? Йолдызлармы?

ИШӘК ИЛӘ САНДУГАЧ.

Ишәк Сандугачны күрде дә, аның янына килеп: «Тыңла әле, дустым! Миңа сине ул сайрарга бик маһир[1] дип мактадылар. Менә мин үз колагым илә синең тавышыңны ишетмәкче вә яхшы-начарлыгын үзем хөкем итмәкче булдым»,— диде.

Сандугач мең төрле көйләргә борып сайрарга кереште.

Ул бер чут-чут итеп куеп, бер сызгыра, бер нәфис тавышын әкренләтеп, бер бөтен урманга вак кына ядрә сибелгән кеби яңгыратып җибәреп, ничек тә булса матуррак сайрарга тырыша иде.

Сайравының тәэсиреннән искән җилләр һәм сайрап торган вак-төяк кошлар туктадылар. Көтүләр бер урынга яттылар.

Шулвакыт безнең Ишәк, маңгаен җиргә куеп:

«Әйе, Сандугач, син һәйбәт сайрыйсың, ләкин шунысы кызганыч: син безнең күршедәге Әтәч белән таныш түгел икәнсең. Әгәр син аның белән танышып, аннан бераз өйрәнсәң, тагы да матуррак сайрар идең»,— диде.

* * *

Ярабби, син безне дә мондый хакимнәрдән[2] сакла.

Габдулла Тукай.

?! Хикәяне «Ишәк үтенече», «Сандугач сайравының матурлыгы», «Сандугачка ишәкнең бәясе» турында дип өлешләргә бүлсәк, бер өлеше артык була. Шул өлешне табыгыз.

---

[1] Маһир — оста.
[2] Хаким — бәя бирүче.

ШАЯН ҖИЛ.

Тып-тын гына торган чакта,
Кинәт җил, әй, кызып китте.
Нур бабайны куып җитте,
Эшләпәсен алып китте.

Бөтерелеп уйный-уйный
Алып китте ерак-ерак.
Бабай, мескен, исе китеп,
Аптырап тик тора карап.

— Әй җил,— дидем,— син нишлисең?
Бабай бит ул — олы кеше.
Йә, күр инде, синең арттан
Куып җитсен соң ул ничек?

Җил уйланып тынып калды,
Авыр итеп бер тын алды.
Борылды да эшләпәне
Кире жиргә илтеп салды.

Ә мин йөгереп кенә китеп,
Барып алдым да ялт итеп,
Бабайга китереп бирдем:
— Менә ал, бабакай,— дидем.
Бабай елмаеп баш иде:
— Вәт рәхмәт, балакай! — диде.

Резеда Вәлиева.

?! **1.** Әсәрдә катнашучыларны әйтегез. Алар арасыннан төп катнашучыларны табыгыз. Ни өчен аларның төп катнашучы булуын исбат итегез.

2. Җил ни өчен бабайга эшләпәсен китереп бирә? Ике сәбәп әйтегез.

3. Әсәрне өч вакыйгага бүлегез.

АШКА ҮПКӘЛӘМӘ.

Төрлесен күрдем тормышта,
Кунагын, башкаларын...
Тик әни пешергән аштан
Тәмле аш ашамадым.
Тәмле аш дигәннән, беркөн
Кайттык та дәресләрдән,
Тиз-тиз генә киемнәрне
Элдек салып өсләрдән.
Кулларны юып утырдык,
Әни аш бүлде аннан.
Мин әйтәм: «Миңа ит бик аз,
Барысын аларга салган...»
Абыйлар карашып куйды.
Торып өстәл янынннан:
— Мин ашамыйм! — дип үпкәләп,
Читкә киттем табыннан.
— Күрше тавыгы күршегә
Күркә булып күренә...
Ашка үпкәләмә, улым,
Бәхет кунмас күңлеңә.
Балалы казга җим тимәс...—
Дип куйды шуннан, мескен.
Үз ашыннан алып салды
Ит кисәгенең берсен.

Шуннан соң бер сүз әйтмәде
Абыйлар да, әни дә:
Элеккедән тәртип шундый
Булганга безнең өйдә.
И ашның тәмле исләре
Борынга бәреп керә...

Алар дәшми, ә мин — кире
Ач калдым шуңа күрә.
Соңыннан бу кирелеккә
Шулкадәр үкенгәнем...
Ник шулчакта әниемнән
Мин гафу үтенмәдем?!
Исләремнән чыкмый һаман
Әнине рәнҗеткәнем.
Үкенәм әле хәзер дә —
Бик зур хата иткәнмен.

Нури Арсланов.

?! 1. Шигырьне ике өлешкә бүлүче вакыйгаларны табыгыз.
2. Икесенә дә исем бирегез.

ӨЧ ГӨЛЧӘЧӘК.

Чәчәкләр илендә булган, ди, бер яшь җырчы. Аның җырларын кешеләр генә түгел, кош-кортлар, агачлар, хәтта бакчадагы чәчәкләр дә тыңларга яратканнар. Җырчының үзе үстергән бакчасында гаҗәеп матур өч гөл чәчәк атып утыра икән.

Бервакыт шулай төнлә җырчыбыз кемнеңдер, үзенә кушылып, нәфис тавыш белән җырлаганын ишетә. Якягына күз сала. Берәү дә күренми. Икенче көнне дә шул ук хәл кабатлана. Өченче көнне, җырына кушылган тавышны ишетү белән, кинәт артына борылып карый. Ә анда бик чибәр бер кыз басып тора икән. Кыз кача башлый.

— Китмә! — ди җырчы. — Тукта, кем син? Син минем җырларымны каян беләсең?

— Мин синең тәрәзә төбеңдә үскән өч гөлчәчәкнең берсе,— ди кыз. — Кояш бату белән, мин кыз сурәтенә керәм. Кояш чыкканда, кабат чәчәккә әверeләм. Чәчәкләрнең таң хәбәрчесе — чык төште инде, җибәр мине, тотма. Мин үз куагыма кайтырга тиеш.

— Синең серле тавышыңны көндез дә ишетәсем килә,— ди җырчы.

— Иртән өч гөлчәчәк арасыннан мине танып алсаң, сихри тылсым юкка чыгар һәм мин кызга әверелермен. Ләкин, кара аны, ялгышма. Ялгышсаң, мин мәңге чәчәк булып калачакмын.

Шулай ди дә кыз юкка чыга.

Кояш чыкканда, җырчыбыз гөлчәчәк куагы янына килә. Күрә: чыкның энҗе бөртекләре чәчәкләрнең нәфис яфракчыкларында калтыраналар. Егет, ялгышудан куркып, чәчәкләргә бик озак карап тора һәм берсеннән:

— Бу син! — дип, өч гөлчәчәкнең берсенә дәшә.

Җырчы күрсәткән гөлчәчәкнең алсу таҗ-яфраклары шунда ук коелып төшә, куак гүзәл кызга әйләнә.

?!

1. Егет кызны ничек таба алган? Аның уен дәвам итегез. Җавап таба алмасагыз, әкиятне тагын бер тапкыр укып чыгыгыз.

2. Беренче вакыйга егетнең кыз белән танышуы турында. Икенче вакыйга ни турында?

ИКЕ САЛКЫН.

Бертуган ике Салкын очрашканнар.

— Әйдә, халыкны туңдырыйк, — ди берсе икенчесенә.

— Туңдыруга килгәндә, мин һәрвакыт әзер. Әйдә, олы юлга чыгыйк. Анда үткән-сүткән кеше күп була, — ди икенчесе.

Чаба-сикерә бара торгач, олы юлга килеп җиткәннәр. Күп тә үтми, пар ат җиккән чана килеп чыккан. Ә чанада, җылы толып киеп, бер сәүдәгәр утыра икән. Бераздан урманга утын алып кайтырга баручы ярлы кешене күргәннәр.

— Туны ертык, бияләйләре тишек, хәзер катырам мин аны. Ә син сәүдәгәр артыннан чап. Мин аны туңдыра алмам,— ди кечесе һәм ярлы артыннан иярә.

Кичен туганнар очрашалар. Өлкән Салкын бияләен бияләенә бәрә-бәрә килә. Ә кечесе ухылдый-ухылдый атлый.

— Сәүдәгәреңне катырдыңмы? — дип сорый кече Салкын.

— Катырдым, — дип җавап бирә өлкән Салкын.

— Бик шәп киенгән иде бит ул. Ничек җиңә алдың? — дип сорый кечесе.

— Мин аның туны, бүреге, итеге эченә кердем дә, кирәкме кирәк, тотындым өшетергә!

— Син ярлы крестьяныңны туңдыра алдыңмы соң? — дип сорый өлкән Салкын.

— Җиңә алмадым аны,— ди кече Салкын. — Туңдырдым, туңдырдым. Ә ул чанасы артыннан төшә дә чаба, төшә дә чаба. Чапкан кешене ничек туңдырмак кирәк. Ярый, урманга барып җит әле. Барыбер кап-

тырам мин сине! Урманга барып җиткән идек, агач кисәргә тотынды. Балтасы белән селтәнгән саен җылына бара. Хәтта туны белән бияләен дә салып куйды. Туны белән бияләе эченә кердем дә, кирәкме кирәк, тотындым туңдырырга. Ә ул утынын кисеп бетерде дә киемнәрен таяк белән бәргәли башлады. Аркам һаман авырта әле.

—Яшь шул әле син, туганкай. Балтаның туннан шәбрәк җылытканын да белмисең. Мин яшәгән кадәр яшәгәч белерсең әле,— дигән өлкән Салкын.

?! Әкият вакыйгасын ике өлеше табылганчы кыскартыгыз.

ИҢ ЗУР КЕШЕ.

Күпне белгән кеше —
Ул зур кеше була...
Куптән-күптән белгән —
Бик зур кеше була.

Бик зур кешегә дә
Тиң зур кеше була.
Әти-әнидән дә
Зуррак кеше булмый:
Шуны белгән кеше —
Иң зур кеше була!

Рөстәм Мингалим.

?! Шигырьне ике өлешкә бүлегез. Соңгы ике юлның мәгънәсен аңлатыгыз.

КАЙТЫЙК ЛА ҮЗЕБЕЗГӘ!

Диңгез матур
Сүз дә юк.
Мондый диңгез
Бездә юк.
Ләкин теге ягына,
Ләкин теге ярына
Йөзеп тә чыгып булмый,
Төбенә чумып булмый.
Тотып булмый балык та,
Юк биредә таллык та.

Тозлы икән суы да —
Чистартмыйлар шуны да.
Эчкә үк кереп булмый,
Иркенләп йөзеп булмый:
«Кермә!» — диеп торалар,
Керсәң, кире боралар.
Кайтыйк ла
Үзебезгә —
Кечкенә
Сөнебезгә.

Роберт Миңнуллин.

?! Автор диңгезне туган авылындагы елга белән чагыштыра. Сөн елгасы матуррак, ди. Тар гына елга ни өчен матуррак икән? Ул балачак истәлекләрен саклавы белән матур. Сез үзегезне диңгез ярындагы авылда үстегез дип күз алдына китерегез һәм, кечкенә генә елга белән чагыштырып, диңгезнең елгадан матуррак булуын исбат итегез.

КӘҖӘ БЕЛӘН КӘБЕСТӘ.

Булган, ди, бер балыкчы,
Иделдә ау салучы,
Булган аның кәҗәсе,
Бүресе, кәбестәсе.

Ул аларны берзаман
Сатарга дип уйлаган.
Алып килеп Казанга
Якшәмбе көн базарда.

Кирәк була боларга
Идел аша чыгарга,
Әмма ничек итәсе?
Балыкчының көймәсе
Кирәгенчә зур булмый,
Дүртесен дә сыйдырмый.
Шуның өчен аңарга,
Идел аша чыкканда,
Туры килә кәҗәне,
Бүрене, кәбестәне
Ташырга берәм-берәм
Шул җайсыз көймә белән.

Ләкин кайсын алдан
Яки кайсын арттан
Алып китәргә ярдан?

Бүрене алып китсә,
Кәҗә белән кәбестә
Теге ярда кала да,

Балыкчы юк арада
Кәҗә ашый кәбестәне.

Кәбестәне чыгарса,
Бүре белән кәҗә калса,
Бүре буа кәҗәне!

Ягез, бер уйлап карыйк:
Ничек итеп чыгарыйк
Идел аша боларны?

Шәйхи Маннур.

Автор соравына җавап бирегез.

АШ АШКА, УРЫНЫ БАШКА.

Ике кеше бәхәсләшкәннәр. Берсе әйткән:

— Шушы кисмәкне, бер дә бушатмыйча, рәттән өч тапкыр тутыра алам, — дигән.

Тегесе ышанмаган:

— Кеше ышанмаслык сүзне чын булса да сөйләмә, — дигән.

Бу кеше кисмәккә тулганчы таш тутырган.

— Тулдымы? — дип сораган. Тегесе:

— Әйе, тулды, — дип җавап биргән.

Шул ук кисмәккә таш арасына ком салган.

— Тулдымы? — дип сораган.

— Тулды, — дигән. Шулар өстенә су койган.

— Тулдымы? — дип сораган.

— Әйе, тулды, — дип җавап биргән.

— Менә шул-шул, — дигән. — Аш ашка, урыны башка дип, юкка гына әйтмиләр аны.

?! 1. Мәзәкне ике өлешкә бүлегез.

2. Бәхәсләшүченең беренчесе кисмәкне ни өчен рәттән өч тапкыр тутырып булмый дип бәхәсләшә? Ялгышын әйтегез.

Мәзәк авторы безгә нәрсә әйтә?

САРАН БЕЛӘН ЮМАРТ.

Борын-борын заманда, карга казначы, козгын азанчы булып торган чагында булган икән, ди, бер Саран белән бер Юмарт. Көннәрдән бер көнне болар юлга чыкканнар. Кич булгач, бер җиргә ашарга утырганнар. Саран әйткән Юмартка:

— Минем капчыкның авызы чишелми, синең ризыкларыңны гына ашап торыйк әле,— дигән.

— Ярый, ашасак ашыйк,— дигән Юмарт.

Ашаганнар Юмарт азыгын. Бер көн ашаганнар болар Юмарт азыгын, ике көн ашаганнар, өченче көнне аның азыгы беткән. Кич булгач, Саран Юмартның йокыга киткәнен саклап кына яткан да торып качкан. Юмарт йокысыннан торса, Саран юк. Юмарт аптырап калмаган, үзенә бер юл белән киткән.

Бара торгач, Юмарт бер йортка килеп җиткән. Йортка керсә, анда беркем юк, ди, өстәл өстендә ярты калач кына ята, ди. Юмарт шул калачтан бер телем генә кисеп ашаган да: «Бу өйнең иясе бардыр әле»,— дип, сәке астына кереп яткан.

Бервакытны бу өйгә Аю, Төлке, Тычкан килеп кергәннәр. Тычкан иптәшләренә әйткән:

—Минем мич башында бер чүлмәк көмешем бар иде, мич башыннан сикереп төшкәндә, ул «чылтырт» итеп кала торган иде,— дигән.

Аю әйткән:

—Минем казылмалы кара юл буенда ат башыдай алтыным бар иде, аны берәү казып караган, аз гына төшеп җитмәгән,— дигән. Төлке әйткән:

—Минем дә казылмалы кара юл янында куй башыдай көмешем бар иде, аны кемдер казып караган, аз гына төшеп җитмәгән,— дигән.

Аю, Төлке, Тычкан, бу өйдә төн кунып, иртә белән тагын чыгып киткәннәр. Болар чыгып киткәч, Юмарт мич башыннан караган икән, анда бер чүлмәк көмеш утыра, ди. Алган бу моны. Аннан киткән казылмалы кара юл белән. Казылмалы юл буендагы ат башыдай алтынны да казып алган. Бераз киткәч, тагын бер казыла башлаган җир күргән. Казып караса, монысында куй башыдай көмеш ята, ди. Аны да алган.

Юмарт, бара торгач, бер урманга барып кергән. Урман эченнән барганда, бер юан имән төбендә тапталган урын күргән дә бу:

—Тукта әле,— дигән,— агач башына менеп утырыйм әле, нәрсә булыр икән? — дигән. Шулай дигән дә агач башына менеп утырган. Кич булып, кояш баегач, имән төбенә җен-пәриләр җыела башлаган. Байтагысы җыелгач, җеннәр башлыгы уртага килеп утырган да әйткән:

—Сукыр җен кайда? — дигән.

Сукыр җен килеп җитмәгән икән, аны алып килергә дип, ике җенне җибәргән. Тегеләр, барып, сукыр җенне бик хөрмәтләп күтәреп алып килгәннәр. Әлеге җеннәр башлыгы бу сукыр җеннән сораган:

— Син нигә соңга калдың? — дигән. Сукыр җен торып әйткән:

— Минем кичегүемнең сәбәбе бар,— дигән.— Мин бер хан кызын сихерләп утырдым, аны инде миннән башка беркем дә дәвалый алмас,— дигән.

— Шулай да ничек дәвалыйсын сөйләп бир,— дигән җеннәрнең олысы. Сукыр җен әйткән:

— Ул ханның,— дигән,— өч ел буена кысыр йөргән бер кара сыеры бар. Әгәр хан шул сыерын суеп ите белән шәһәр халкын сыйласа, кыз, һичшиксез, савыгыр,— дигән.

Таң атуга, җеннәр тагын таралып беткәннәр.

Юмарт туп-туры әлеге хан шәһәренә киткән. Барып җиткәч, шәһәр читендәге бер ялгыз йортка кергән. Исәнлек-саулык сорашкач:

— Йә, хуҗа, сезнең шәһәрдә нинди яңалыклар бар? — дип сораган.

— Яңалык шул,— дигән йорт хуҗасы,— безнең ханның кызы бик авырып китте, аның авыруына дару тапкан кешегә хан үзенең ханлыгын да, кызын да бирергә булды,— дигән.

— Ярый,— дигән Юмарт,— мин хан янына барып карыйм әле,— дигән.

Барган бу сарайга. Сарай сакчыларына үзенең дәвалаучы икәнен әйтеп, хан янына керергә рөхсәт сораган. Хан бу кешене сарайга кертергә кушкан. Кергәннән соң, Юмарт үзенең китабын караган була икән. Китабына карап торганнан соң әйткән бу:

— Синең көтүеңдә өч ел кысыр калган бер кара сыерың булыр, шул сыерны суеп, шәһәр халкын ашатып-эчертсәң, кызың терелер,— дигән.

Хан, моңа риза булып, нәкъ Юмарт әйткәнчә эш-

ләгән. Күп тә узмаган, берничә көннән соң ханның кызы терелгән. Хан Юмартка үзенең кызын да, ханлыгын да биргән.

Көннәрдән бер көнне әлеге Саран да шушы шәһәргә килеп чыккан. Юмарт янына кереп, аннан ничек хан булуы, ничек патша кызына өйләнүе турында сораша башлаган. Юмарт моңа башыннан кичергәннәрнең барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп биргән.

Саран моның болай тиз баюына бик кызыккан. Ул да чыгып киткән, киекләр торган йортны эзләп. Барып кергән бу әлеге өй эченә. Барып керсә, өстәлдә баягыча ярты калач ята, ди...

?! Әкиятнең икенче өлеше юк. Аны табу өчен, беренче өлештәге вакыйгаларны яхшы белергә кирәк. Ә икенче өлеш беренчесенең капма-каршысы булуын беләсез.

Әкиятнең дәвамын (икенче өлешен) языгыз.

Бөтенлек.

Чаңгыга бассагыз, сез чаңгычы буласыз. Чаңгы, аның таяклары һәм сез бербөтенгә әйләнәсез. Җигүле ат та бербөтен, ә бит аңа чана тагылган, таякка таянып баручы әбигә дә «әнә әби белән таяк килә» димиләр. Машинаның да частьлары (өлешләре) күренеп тормый. Ә сүтә башласаң, андагы детальләрне санап бетерерлек түгел. Менә сез өегезгә кайттыгыз, ди. Башта аяк киемегезне салдыгыз, аннары пальтогызны, баш киемегезне элеп куйдыгыз. Димәк, сез үзегез дә әллә ничә өлештән торасыз икән бит.

Менә шундый үзара тыгыз бәйләнгән өлешләргә **бөтенлек** диләр.

Мондый бөтенлекләрне өлешләргә аеру җиңел. Чөнки аларның өлешләре күренеп тора. Ә бит өлешләре күренми торган бөтенлекләр дә күп.

Мәсәлән, сез өйдә эш кушканны көтеп тормыйсыз, ди. Себерәсез, юасыз, ташыйсыз, түгәсез, чистартасыз. Әбиегез шуның өчен «эшчән» дип мактый. Ләкин, дәрескә әзерлексез килгән өчен, укытучыгыз сезне «ялкау» дип оялта. Менә шул рәвешле берничек тә икегә аерылмый торган укучы капма-каршы якларга аерыла да куя.

Әдәби әсәрләрдә дә шулай: бөтенлекләр көтмәгәндә үзләренең каршы якларына аерылалар да куялар.

Әйберләрне, күренешләрне, вакыйгаларны әйткән дә юк. Хәтта кеп-кечкенә сүзләр дә үзләре бербөтен, ә уенчыкларны сүткән кебек сүтеп карасаң, әллә ничә кисәктән тора икән.

?! Язманы ашыкмыйча укып чыгыгыз. Сөйләргә уңайлы булсын өчен, текстның планын төзеп, дәфтәрләрегезгә язып куегыз.

НАИЛ АРКАСЫНДА.

Наилнең әнисе күршеләргә зарлана:

— Безнең Наил аркасында өч килограмм йон кыркылмый калды,— ди. Күршеләре шаккаталар:

— Шундый кечкенә малай аркасында әнә никадәр йон үскән бит! — диләр.

Икенче көнне хикмәтле Наил аркасын карарга бөтен авыл җыела.

Ләкин Наил аркасын күрсәтергә өлгерми кала. Әнисе тамаша карарга килүчеләргә ни булганын аңлатып бирә.

Наил, футбол уйнап, көтү кайтканын күрми калган. Сарыклары өйләренә кайтмаган. Шул көнне Наил әнисе сарыкларының йонын кыркырга җыенган булган. Наилнең җавапсызлыгы аркасында сарыклар кыркылмый калган икән.

Альберт Гатуф.

?! **1.** Хикәянең ике өлешен һәм аларны бөтен итеп торучы бәйләнешне табыйк.

2. Башта күршеләр Наилнең аркасына шулкадәр озын һәм күп йон үскән дип шаккатканнар. Бу хәбәр эчендә тагын бер хәбәр посып яткан икән. Әнисе аңлатып биргән: йон Наилнең аркасында үсмәгән, ә аның җавапсызлыгы аркасында сарыклары кыркылмый калган.

Шундый төрле ике хәбәр бер генә хәбәр булып ничек кушылганнар соң?

Аларны «аркасында» сүзе бәйләп куйган икән. Бу сүзнең ике мәгънәсе бар. Шуңа күрә шул бер сүз хәбәрне әле аерып, әле кушып тора.

ЮГАЛГАНМЫ?

— Әти, әгәр дә мин синең ун япьле пәкеңнең кайда икәнлеген белсәм, пәке югалган буламы? — дип сораган улы әтисеннән.

— Кайда икәнен белсәң, нишләп югалган саналсын? — дигән әтисе.

— Алайса, мин аның кайда икәнлеген беләм. Мин аны ялгыш урманда төшереп калдырдым,— дигән улы.

?! Мәзәктә ике өлешне кушып торучы бәйләнешне табыгыз.

ШӘВӘЛИ СӘГАТЕ.

Миңа булды бит әле
Әтиемнең сәгате!
Сәгате дә сәгате —
Әйбәтнең дә әйбәте!

Әйтерсең лә яхшы ат,
Чаба гына, сыптыра —
Өйдә ничә сәгать бар,
Һәммәсен узып тора!

Шәүкәт Галиев.

?! Шигырьдәге барысын да узучы сәгатьнең төп сыйфатын бер-ике генә сүз белән әйтегез.

ҖИЛ НИНДИ?

Җил тузына —
Агачларны
Йолкып-йолкып ташладым, ди.
Ачуымнан юлчыларга
Каршы исә башладым, ди.

Җил шаяра —
Бер абзыйның
Эшләпәсен очырдым, ди.
Күлләвеккә барып төшкәч,
Үзем бик тә борчылдым, ди.
Җил масая —
Йөгерә-йөгерә,
Аякларым талдырдым, ди.

Болытларны җыеп килеп,
Җылы яңгыр яудырдым, ди.
Җыеп элгән
Ак керләрне киптердем, ди.
Үзегезгә болыннарның
Хуш исләрен китердем, ди.

Лена Шагыйрьҗан.

?! 1. Автор соравына җавап бирсәгез, бөтенлекнең каршы якларга аерылуын күрерсез. Җил нинди?

2. Җилне укучыга охшатыйк. Җилгә охшаган укучыга бәя бирегез.

КИЧӘ ГЕНӘ.

Кичә генә яшел иде
Зәй буенда үләннәр.
Бүген алар әллә нишләп
Көрән төскә кергәннәр.

Кичә генә яшел иде
Зәй буенда таллар да.
Бүген әнә коңгырт төстә —
Нәрсә булган аларга?

Кичә генә яшел ярлар
Бүген сары киемнән.
Киемнәрен алыштырып,
Зәй буенда кем йөргән?

Клара Булатова.

?! Зәй буенда көз йөргән. Көзне бөтенлек итүче сыйфатларны табыгыз.

АНДЫЙ БУЛМАГЫЗ.

Бәхетле була балалар,
Әби белән үссәләр.
Әби сүзен тыңласалар,
Аны тота белсәләр.

Начарлыкка өйрәтми бит
Бер әби дә баласын.
Әби сүзен тыңламасаң,
Юньсез булып каласың.

Мин әбинең сүзен тыңлыйм:
— Ярар, ярар, — дип торам.
Кушканын гына эшләмим,
Әле уйнап утырам.

— Эш беткәч уйнарга ярый, —
Дигән дә Тукай бабай...
— Уйнап туйгач эшләрмен, — дип
Үсәм мин юньсез малай.

Мин кемгә дә үрнәк түгел,
Ә сез андый булмагыз.
Эш беткәч кенә уйнагыз,
Әби сүзен тыңлагыз.

Клара Булатова.

?! Малайга бәя бирегез: ул юньле малаймы, юкмы?

КЫШ ҺӘМ КЕШЕ.

Кыш бабай килгән,
Ап-ак тун кигән,
Көтә, кем генә
Чыгар, дип өйдән.

Чыксак — чеметә,
Битне өшетә,
Менә шул аның
Бөтен эше дә.

Суык тутырган
Капчыгын чишә:
Буран кузгала,
Салкын җил исә.

Менә күзенә
Кеше күренә.
Әй шатлана Кыш,
Аны күрүгә.

Агач кисәргә
Тотына кеше,
Кисешә бергә
Аның күршесе.

Кыш әйтә аңа:
— Сынашыйк көч,— ди.
Битен чеметә,
Колагын тешли.

Кеше бирешми,
Эшли дә эшли.
— Маташма, юкка,
Туңмыйм мин, Кыш! — ди.

Кышны үчекли:
— Хәлең ничек? — ди.—
Кил, син дә җылын,
Агач кисеп,— ди.—

Менә мин эшлим,
Эш белән дус мин,
Шуңа күрә дә
Сиңа бирешмим. —

Кыш китә. Алда
Зур өй күренә.
Уйлый ул менә
Шунда керергә.

Чеметер иде
Битен таш өйнең,
Капшап карый ул
Аның бар җирен.

Барып чыкмый һич,
Ул да бирешми:
Өйдә җып-җылы
Батарея эшли.

Икенче өйгә
Ул башын тыга,
Булмый керергә,—
Газ янып тора.

— Моның барысы
Эшнең көче,— ди.—
Кеше эше,— ди.—
Ах, син, кеше! — ди.

Бари Рәхмәт.

?! **1.** Баштагы өч дүртьюллыктагы вакыйганы үз сүзләрегез белән сөйләгез. Вакыйгага бик кыска исем бирегез.

2. Калган дүртьюллыкларны да үз сүзләрегез белән сөйләгез. Андагы өч охшаш вакыйгага уртак исем уйлап табыгыз.

3. Шигырьне сез ничек тәмамлар идегез?

Әсәрне охшаш өлешләрен кушып бүлү.

Үсеп утыручы каенны, тамыры, кәүсәсе, ботаклары, яфраклары дип, дүрт өлешкә бүләбез. Тамырлары, ботаклары, яфраклары күп бит, ни өчен дүрт кенә өлешкә калдырдык? Менә ни өчен: яфраклары күп, ләкин алар охшашлар, дидек тә куштык. Кушу өчен, күп өлешләрнең барысына бер генә исем бирдек. «Яфраклар» дидек. Дәвам итегез.

Авторлар охшаш сүзләрне, шигырь юлларын, күренешләрне кабатларга яраталар. Әкиятләрдә хәтта зур-зур вакыйгаларның да кабатлануын күрдек. Без кабатланган урыннарны эзләп табабыз да «болар охшаганнар» дип кушабыз. Башкача әйтсәк, барысына да уртак булган исем уйлап табабыз.

ЧЫРШЫ.

Саргаядыр көз көнендә һәр агач яфраклары;
Юк яшеллекләр хәзер, урман вә сахра сап-сары.

Саргая таллар, усаклар, алмагачлар һәм каен;
Хәстә[1] төсле, арта сары төс аларда көн саен.

Үз төсен үзгәртми саклаучы арада берсе бар:
Көз көне һәм кыш буе саргаймый торган чыршы бар.

Габдулла Тукай.

?! Баштагы ике юлда урман да, сахра да сап-сары, ди автор. Уртак сыйфатларын бер сүз белән генә әйтеп бирде. Димәк, «сарылык» сүзе бу өлешнең исеме була ала. Шул исем эченә яфраклар да, урман да, сахра да керде.

---

[1] Хәстә — авыру кеше.

Шигырьдәге башка охшаш күренешләрне дә куып, аңа исем бирсәгез, әсәр төзелешенең бер өлешен табасыз.

Шигырьнең икенче өлешен табыгыз. Аңа да исем бирегез.

КОЯШНЫҢ НУРЛАРЫ.

Матур кояш иртә белән кызарып күк йөзенә күтәрелде. Җир йөзен татлы йокысыннан уятыр өчен, алтын кебек сары якты нурларын, таратып, төрле якларга җибәрде.

Башта бер нур очты. Барып-барып, сабан тургаеның өстенә төшкән иде, сабан тургае йокысыннан уянып тирбәнде, чыгып күк йөзенә күтәрелде. Шуннан матур тавыш белән чырлап сайрап җибәрде.

Икенче нур очты. Монысы татлы йокыда яткан куян өстенә барып төште. Куян, урыныннан торып, озын колакларын селкетте. Шуннан, сикерә-сикерә, яшел тугай эченә төшеп, йомшак үләннәрне керт-керт өзеп ашарга кереште.

Янә бер нур, очып, тавык кетәгенең эченә кергән иде, өлкән әтәч, күзләрен ачып, канатларын язып, гайрәт белән тилпенде. «Кикри-и-и-и-кү-ү-ү-к!» — дип кычкырып җибәрде. Тавыклар куанычларыннан очышып төштеләр. Кытаклашып, төрлесе төрле якка таралды җим эзләргә.

Дүртенче нур, килеп, умарта өстенә төшкән иде, бал корты, балавыз сараеннан чыгып, канаткайларын төзәтте. Шуннан «Без-з-з-з!» китте очып хуш исле чәчәкләрдән татлы бал җыйнарга...

Бишенче нур...

Дәрдемәнд.

?! **1.** Әсәр тәмамланмады. Китерелгән беренче өлештә вакыйгалар күп. Аларны кушыгыз. Барысына бер исем уйлап табыгыз.

2. Хикәянең автор язган дәвамы нинди булырга мөмкин? Дәвамын дәфтәрләрегезгә языгыз.

Җавабыгызны хикәянең соңгы сүзләреннән башлап җибәрегез: Бишенче нур... (Кемгә төшә?)

ҮГИ КЫЗ.

Бер ир белән хатын була, аларның бер кызлары була. Бик әйбәт кенә торганда, моның әнисе авырып үлеп тә китә. Әтисе икенче хатынга өйләнә. Аның да бер кыз баласы була.

Бервакытны әтиләре тегермәнгә киткәч, кызлар җыярга булалар. Бик күп иттереп, өйне тутырып җыялар болар. Үги кызга ызбада утырырга урын да калмый, шулхәтле күп җыялар инде. Үги ана сукыр лампага ут төртә дә, үги кызның кулына тоттырып, мунчага илтеп куя: «Бүгенгә син шунда утырырсың»,— ди. Үзенең эрли торган җепләрен илтеп бирә. Кыз, курка-курка, мунчада җеп эрләп утырганда, ап-ак чәчле бер әби килә тегенең янына. Әби әйтә:

— Әйдә, кызым, безгә,
Безнекеләр байлар,
Ашыйлар да эчәләр,
Уйныйлар да көләләр,—

ди.

— Әй әби, бик барыр идем дә мин сезгә, өстемә кияргә күлмәгем дә юк бит, нәрсә киеп барыйм соң? — ди кыз. Шул арада теге карчык йөгереп күлмәк китереп җиткерә: «Мә, кызым, ки»,— дип. Карчык, күлмәк китергәч, тагын:

— Әйдә, кызым, безгә,
Безнекеләр байлар,
Ашыйлар да эчәләр,
Уйныйлар да көләләр,
Сиңа күңелсез булмас,—

ди.

— Әй әби,— ди кыз,— бик барыр идем дә, минем бит башыма шәлем дә юк,— ди. Әби моңа йөгереп шәл дә китерә. Аннан яңадан:

— Әйдә, кызым, безгә,
Безнекеләр байлар,
Ашыйлар да эчәләр,
Уйныйлар да көләләр,—

ди.

— Әй әби, бик барыр идем дә, минем аягыма киеп барырга читек-кәвешем юк бит,— ди.

Әби моңа йөгереп кенә читек-кәвеш тә китерә. Әби тагын:

— Әйдә, кызым, безгә,
Безнекеләр байлар,
Ашыйлар да эчәләр,
Уйныйлар да көләләр,—

ди.

— Әй әби, мин сезгә барыр идем дә, сезгә баргач ябынып ятарга юрганым юк бит,— ди.

Карчык шундук йөгереп юрган китерә моңарга.

— Әйдә, кызым, безгә,
Безнекеләр байлар,
Ашыйлар да эчәләр,
Уйныйлар да көләләр,—

ди карчык яңадан.

— Әй әби, мин сезгә бик барыр идем дә бит, сезгә баргач ябынып ятарга юрганым булды, баш астыма салып ятарга мендәрем юк,— ди.

Карчык шундук йөгереп мендәр китереп җиткерә.

—Әйдә, кызым, безгә,
Безнекеләр байлар,
Ашыйлар да эчәләр,
Уйныйлар да көләләр,— ди.

—Әй әби, бик барыр идем мин сезгә, анда баргач кияргә минем алмаш күлмәгем дә, корырга чыбылдыгым[1] да, сөртенергә сөлгем дә юк бит, нишләрмен икән соң? — ди.

Карчык тагын йөгереп кенә кыз сораган әйберләрнең барысын да берәм-берәм китереп җиткерә. Әйберләрен салырга дип, сандыкны да дырылдатып китереп бирә дә әйтә:

—Әйдә, кызым, безгә,
Безнекеләр байлар,
Ашыйлар да эчәләр,
Уйныйлар да көләләр,
Җитмәгән әйберең безгә баргач булыр,—

ди.

Кыз: «Нәрсә генә әйтим икән инде, бөтен әйберем дә булды бит»,— дип уйланып торганда, таң әтәче кычкырып җибәрә дә, әтәч тавышын ишетүгә, карчык юкка чыга. Шуннан таң ата, байтак кына вакытлар үткәч, әнисе: «Кыз нишләп утыра икән?» — дип килеп караса, кыз киенгән, ясанган, зур сандык өстенә утырып, җеп эрләп утыра, ди. Хатын бу хәлне күргәч гаҗәпкә кала. Икәүләп, сандыкны ике яктан тотып, өйгә кайталар. Хатын моның әйберләренә бик кызыкты бит инде. «Бүген кечкә үземнең кызымны да мунчага җибәрәм»,— ди.

---

[1] Чыбылдык — бүлмәнең берәр урынын, мәсәлән, караватны бөтен яктан каплап алу өчен куела торган пәрдә, чаршау.

Тагын шулай күп итеп кызлар җыялар, үги кыз өйдә кунаклар янында кала, ә үз кызын сукыр лампа яндырып мунчага илтә. Бераз утыргач, әлеге әби-карчык килеп керә дә:

— Әйдә, кызым, безгә,
Безнекеләр байлар,
Ашыйлар да эчәләр,
Уйныйлар да көләләр,—

ди.

Үги кыз сөйләгән була бит инде ничек баюы турында. Бу да, тегенең кебек:

— Әй әби, бик барыр идем дә, минем өстемә кияргә күлмәгем юк бит,— ди.

— Әй юньсез, ди, ник алдыйсың мине, өстеңә кигән күлмәгең нинди яхшы,— дип...

?! 1. Әкиятне дәреслектә язганны кабатламаска тырышып сөйләгез. Аннан соң иң мөһим вакыйгаларын гына, әкият хәтерегездә ничек калган, шулай сөйләгез.

Әкиятне, «Үги кыз» һәм «Үги ананың үз кызы» турында дип, ике өлешкә бүләбез.

Беренче өлештәге уртак вакыйгаларны кушып, бергә генә калдырыгыз. Моның өчен барысына бер исем бирергә кирәклеген беләсез. Шулай итегез.

2. Әкиятне укып чыккач күрдегез: икенче өлеш беренчесенең капма-каршысы булырга тиеш. Охшаш вакыйгаларның уртак эчтәлеген үз сүзләрегез белән әйтегез. Әкиятне тәмамлагыз.

КЫШ УСАЛЛЫГЫ.

Кышның нәрсәгәдер ачуы килде. Ни күрсә, шуны туңдырырга карар кылды.

Салкынын өрде — тирә-юньгә яфраклар чәчеп ташлады. Җылыныр урын таба алмагач, кошларның бер

ише усал кыш булмый торган якларга очып киттеләр. Калганнары, ышык эзләп, бүрәнә ярыкларына кереп постылар. Кошларны туңдыра алмагач, кыш, гайрәтләнеп, җанварларга ябышты. Бөтен җиргә кар сибеп чыкты да җанварларны катырырга кушты. Җиргә салкын артыннан салкын өрде. Салкыннар берсеннән-берсе зәһәррәк булды. Җанварлар ояларына кереп качтылар. Ә балыклар боз астында туңмадылар.

Усал кыш кешеләргә һөҗүм итте. Тәрәзәләрен бозлы чәчәкләр белән каплады. Ә кешеләр мичләренә ягып җибәрделәр. Утын әзерләделәр. Утыннарын чанага төяп ташыдылар.

— Ай-һай әйбәт салкыннар килде,— дип, кышны мактый-мактый кайттылар.

Кыштан хәтта балалар да курыкмады. Урамга чабып чыктылар да чана шуып уйнадылар. Кыш ачу белән берәрсенең колагын чеметеп алса, бала шунда ук колагын учы белән уды. Шуннан соң йөзе алма кебек кып-кызыл булып кызарды.

Кыш үксеп-үксеп елады. Кышның күз яшьләре җиргә тамдылар да тамдылар. Кыш җиңелде. Моннан китәргә җыенды...

Константин Ушинский буенча.

?! Хикәяне ике генә катнашучыга калдырып бүлегез.

БИЛГЕЛЕ УРЫН.

Безнең өйдә бар нәрсә
Үз урынын шәп белә:
Пальто чөйгә эленә,
Китап киштәгә менә.

Бияләйләр, оеклар
Җылыны яраталар —
Яккан мич кырыенда
Рәхәтләнеп яталар.

Һәрнәрсә дә урынлы.
Тәртипле машиналар,
Уенчыклар, уйнап туйгач,
Тартмага ашыгалар.

Мендәрләр ята диванда,
Күлмәк-чалбар шкафта,
Алай-болай дәрес бозсам,
Миңа дигән урын да бар
....

Йолдыз.

?! 1. Шигырьдәге охшаш өлешләрне кушып, исем бирегез.
2. Әсәрнең икенче өлешен табыгыз.

Әсәрнең икенче өлеше күп нокталар урынында.

Шушы урында туктап торыйк та тагын бер кагыйдә турында уйланыйк.

Күп әсәрләргә анализ ясадык. Аларны өлешләргә бүлдек тә охшаганнарын куштык. Шулай итеп, әсәрләрнең барысы да ике генә өлешкә калуын үз күзебез белән күрдек. Әсәрләрнең эчтәлекләре дә, вакыйгалары да төрле-төрле, катнашучылар да башка булуын белдек. Ә аларның төзелешләре бертөсле икән.

Әйдәгез, бергәләп кагыйдәсен дә язып куйыйк.

Бик күп әсәрне ике генә өлешкә калдыру өчен, андагы охшаш катнашучыларны кушарга кирәк. Кушылмаганы икенче өлеш була.

ШАУЛАМАГЫЗ, ӘТИ ЙОКЛЫЙ.

Без инде күптән уяндык,
Тышта кояш яп-якты.
Төнге сменадан кайтып,
Әти йокларга ятты.

Безгә әйтте шауламаска,
Дөбер-шатыр килмәскә.
Киләбезме соң, килмибез —
Шуны гына белмәскә!

Йөрибез әкерен генә,
Аяк очына басып.
Сөйләшсәк тә сөйләшәбез,
Үзара пышылдашып.

— Тсс, Фәсхетдин, сызгырынма!
— Искәндәр, куй чүкечне!
— Тәнзилә, дим, саграк кылан,
Шалтыратма чүмечне!

— Әти йоклый, шауламагыз!
Сиңа әйтәм, Сәгадәт!
— Сөгъдәне ник елатасың,
Гайнулла, бу ни гадәт?

— Фирая, җитте сиңа да,
Шудырма урындыкны!
— Илһамия, сикерергә
Урамда урын юкмы?

Шыпырт кына чыгып эти
Карап торган ишектән.
Шулхәтле ду килүгә соң
Ишеткәндер, ишеткән...

Бер-беребезне тыя-тыя,
Шундый кызып киткәнбез —
«Кычкырма!» да «Шаулама!» дип
Шаулашабыз икән без...

Шәүкәт Галиев.

?! **1.** Шигырьне «Эти һәм без» дип бүлеп була. Ни өчен? Шигырьдә катнашучылар күп бит.

2. Ләкин сез аны башкача бүлеп карагыз. Моның өчен шигырьне тагын бер кат укып чыгыгыз.

Күнегүләр үткәрик.

ИҢ ТӘМЛЕ ИКМӘК.

Купты магазинда бәхәс,
сөйләшәләр гөр дә гөр:
«Тәмле икмәк арасында
иң тәмлесе нинди төр?»

Сатучы да сүзгә кушыла:
— Күп күрдем, димәк, беләм:
иң тәмле икмәк — ак икмәк.
Пешерелә мәк белән.

— Ә йөземлесе! — ди берәү.—
Кабасың икмәк диеп,
чәйнисең йөзем җимеше...
Исең киткән мәк диеп!

Бер икмәкне мактый-мактый
килеп керә бер әби:
— Бауман урамында алдым...
түгәрәкне... Менә! — ди.—

Вәт бер кисәге, карагыз,
Аккош мамыгы бит, ә!
Нинди зур кисәк, ә кыскач
учыңа сыеп бетә!

Учыңны ач — мендәр була...
Хәзерге заманда да
шәп икмәк пешерүчеләр
бар бит, әй, Казанда да!

Шунда чемодан күтәргән
эшләпәле бер абый,
чемоданын куяр өчен,
җайлырак урын карый.

Аннан, бер икмәк чыгарып:
— Карагыз,— ди Эшләпә,—
Мәскәүнеке, горчичный,— ди
һәм әбигә тешләтә.

Ләкин җиңеп чыга алмый
гәрчиче дә, балы да.
Тик үзе яраткан төрне
мактый бирә бары да...

Кerə ак сакаллы бер карт,
нəкъ шул чагында килеп.
Әйтәләр: «Һəммəбез риза,
шул хөкем итсен!» — диеп,—

Әйт, бабай, хəл ит бəхəсне!»
Сорый карт: «Эш нəрсəдə?»
Аңлаттылар һəм тыңдылар.
Хəл ителə мəсьəлə...

Картның сүзен беравыздан
«Дөрес!» — диделəр, җөплəп.
Ә карт әйтте: «Иң тәмлесе —
эшлəп ашаган икмəк».

Салих Баттал.

1. Шигырьнең беренче өлешенә берничә охшаш вакыйга керə. Шуларны кушып, уртак исем бирегез.

2. Икенче өлешне табыгыз.

3. Ике өлешне кушып сөйлəгез.

4. Түбəндəге мəкальлəрнең кайсылары əсəргə исем була ала?

* Эшлəгəн ашый, эшлəмəгəн баш кашый.
* Эшлəргə иренсəң, ашарга көрсенерсең.
* Тирлəп эшлəсəң, тəмлəп ашарсың.
* Эшенə күрə ашы.
* Эшлəп ашасаң, арыш ипиеннəн дə күмəч тəме килə.

ҺӨНƏРЛЕ ҮЛМƏС.

Әүвəл булган, ди, бер бик ярлы кеше. Аның булган, ди, өч улы. Бөтен байлыгы бер балтасы, бер көрəге, бер мунчаласы булган, ди.

Картаеп авырый башлагач, бу кеше улларына бөтен байлыгын бүлеп биргән, ди. Берсенә — балта, икенчесенә — көрәк, өченчесенә мунчала тиде, ди. Уллары үзләренә тигән өлешләрен алып киттеләр, ди, чыгып.

Бара торгач, барып җиттеләр, ди, бер авылга. Бу авылда бер балта да юк икән, ди. Бер бай үзенә өй салдырган, ди, өенең бер тәрәзәсе дә юк, ди. Бу бай иләк белән өенә яктылык ташырга ике хезмәтче яллаган, ди. Хезмәтчеләр ташый-ташый, ди, иләкләренә тутырып яктылыкны, тик кояш яктысы тәрәзәсез өйгә керми, ди.

— Өеңә кояш яктысы кертсәм, күпме акча бирәсең,— дип әйткән ди балталы агалары.

— Кояш чыгып баеганчы өйдә яктылык торса, мең тәңкә бирәм,— дип ышандырган, ди, бай.

Балталы кеше балтасы белән өйнең өч ягына тәрәзә куйды, ди. Шуннан соң өй яп-якты булды, ди. Моңа бай мең тәңкә акча биреп җибәрде, ди. Егет бик баеп кайтты, ди.

?! Әкият адәм ышанмаслык вакыйгалары белән матур. Ул матурлыкны әкият авторлары уйлап тапканнар. Укыган өзектәге матур урынны табыгыз.

Моны күргәч, уртанчы агалары да көрәген күтәреп чыгып китте, ди. Бик озак баргач барып җитте, ди, бер авылга. Бу авылда Иделдәге боз өстендә бик күп ашлык сукканнар, ди. Көн бик суык, ди. Боларның көрәкләре юк, ди. Ашлыкны кул белән җилгәрәләр, ди.

— Ике көндә җилгәреп бетерсәм, ни бирәсез? — дип сораган уртанчы егет. Тегеләр ашлыкларының

яртысын бирергә булдылар, ди. Бу кеше көн ярымда җилгәреп, ашлык алып кайтып китте, ди.

?! Бу әзектә дә кеше ышанмаслык вакыйга бар. Шуны табыгыз.

Өлкән агаларының баеп кайтуын күреп торган кече энеләре, мунчаласын сөйрәп, су буйлап китте, ди. Бара торгач, бер зур күл буена туктады, ди. Бу күлне электән пәриләр күле дип йөртәләр, ди. Бу кеше ярга утырды да, ди, мунчаласыннан бау ишә башлады, ди. Бераз ишкәч, күлдән бер пәри баласы чыкты, ди.

— Агай, бу бау нигә? — дип сорады, ди, пәри баласы.

— Менә бу күлне күккә асып куям,— дип әйтте, ди, егет.

Пәри баласы күл төбенә төшеп китте дә, ди, бабасына әйтте, ди:

— Харап булдык, бабай, теге егет күлне күккә асмакчы була,— диде, ди.

— Курыкма, сез аның белән йөгерешерсез. Кем узса, шул җиңгән булыр,— дип киңәш бирде, ди, бабасы.

Теге кеше ул арада тау буеннан ике куян тотып алды да, ди, күлмәк эченә тыгып куйды, ди.

Пәри баласы судан чыгып, әйдә, узышыйк, кем узса, шул откан булыр, дип әйтте, ди.

— Ярар. Үзем урынына ике айлык улым барыр,— дип, куяннарның берсен чыгарып җибәрде, ди, егет. Пәри аны куып җитә алмады, ди. Бу кеше, пәри әйләнеп килгәндә, куенындагы икенче куянны тотып:

— Әй гөлкәем, арыгансыңдыр инде,— дип сөеп утыра, ди. Пәринең моны күреп исе киткән, ди.

Пәри тагын бабасы янына керде, ди.

— Теге егетнең ике айлык улы бар икән, бабай, мине шул улы да узды, — дип әйтте, ди. Карт пәри бу юлы егет белән көрәшергә кушты, ди.

Яшь пәри егеткә:

— Әйдә, көрәшик,— диган, ди. Кеше аңа әйтте, ди:

— Әнә теге агач төбенә төзәп ат та: «Әйдә, көрәшик»,— дип кычкыр. Анда минем карт бабам юкә юнып утыра. Шуның белән көрәшерсең,— диде, ди. Пәри таш аткан иде, ди, ташы аю башына тиде, ди. Аю ачуланып ябышты, ди, моңа. Көчкә качып котылды, ди, пәри.

Тагын бабасы янына йөгереп керде, ди.

— Бабай, аның теше төшеп беткән бабасы да мине җиңде,— дип әйтте, ди.

Бабасы моңа кырык потлы тимер таяк биреп чыгарды, ди.

— Чөешегез, кайсыгыз биегрәк чөйсә, эш шуныкы булыр,— дип әйтте, ди.

Пәри чыкты да, ди, таякны чөеп җибәрде, ди. Таяк, күз күреме биеклеккә менеп, кабат әйләнеп төште, ди.

Таяк төшкәч, теге кеше чөйми тик тора, ди.

— Ник чөймисең, агай, без җиңдекме? — дигән, ди, пәри.

— Ашыкма. Әнә теге болыт килеп җитсен, таякны шуның өстенә ташлыйм,— дигән, ди, егет.

— Берүк ташлый күрмә, бабай ачуланыр,— дип,

пәри, таякны алып, бабасы янына керен китте, ди. Кергәч, бабасына әйтте, ди:

— Бабай, теге кеше таякны аздан гына болыт өстенә куеп җибәрмәде, мин генә тотып калдым,— диде, ди.

— Бар, сора, күпме акча алмакчы,— дип әйтте, ди, карт пәри.

Пәри баласы чыгып сораган иде, ди, егет аңа:

— Минә шушы эшләпәмне көмеш тәңкәләр белән тутырсагыз җитә,— дип әйтте, ди.

Пәри керен киткәч, егет бик тирән чокыр казыды, ди. Чокыры өстенә эшләпәсенең төбен тишеп куйды, ди. Теге пәри көмеш тәңкәләрен ташый-ташый тәмам хәлдән тайды, ди.

Чокыры акча белән тулгач, егет, чокыр авызын каплап кайтып китте, ди.

Шуннан соң, күршеләреннән ат алып, акчаларын көне буе ташыды, ди.

?! **1.** Алдагы ике өзектә егетләр ничек баедылар? Җавапны, бик кыска итеп, бер генә сүз белән әйтегез.

2. Ике егет эшләп баеды (беренче өлеш), энеләре ничек баеды?

3. Соңгы өзекнең үзендә адәм ышанмаслык өч вакыйга бар. Беренчесе мондый: егет, күлне күккә асам, дип куркыта. Калганнарын әйтегез.

Кеше сыйфатының дәрәҗәсен сурәтләү.

Без сыйфатның да, дәрәҗәнең дә ни икәнлеген беләбез инде. Искә төшерик.

«Сыйфат» төшенчәсе күнекмәгәнгә генә колакка ятышсыз сүз булып яңгырый. Чынлыкта бик бай, матур, эшчән сүз ул. Ничек бай булмасын — кешенең акылына, наданлыгына, көченә, юмартлыгына, ялкаулыгына, уңганлыгына да сыйфат диләр.

«Сыйфат» сүзе ничек эшчән булмасын? Без бит аны дәрес саен әллә ничә мәртәбә кулланабыз.

«Дәрәҗә» — сыйфатның иң якын дусты. Алар арасына кыл да сыймый. «Дәрәҗә» сүзе сыйфатны үстерә ала. Киметергә теләсә киметә. Ялкаулык — кешенең шактый ямьсез сыйфаты. Кеше ялкаурак, ялкау, бик ялкау була ала. Менә шундый үсешкә **ялкаулык дәрәҗәсе** диләр.

Кеше сыйфаты дип, гадәттә, аның холкына әйтәләр. Ләкин кешенең мәхәббәте дә, үкенече дә, нәфрәте дә, яхшы укуы да, кирелеге дә, ялкаулыгы, әдәплелеге дә — бар да кеше сыйфатлары.

Мактанчык, бик мактанчык, түзеп тора алмаслык дәрәҗәдә мактанчык кешеләр була. Сыйфатларның менә шундый үсешенә яки кимүенә **сыйфат дәрәҗәсе** диләр.

Без барыбыз да беркадәр арттырырга яратабыз. «Мин кайтканда караңгы иде» димибез, «күзгә төртсәң

күренми иде» дибез. «Оялдым» димибез, «җир ярылса, җир астына төшеп китәрлек булдым» дибез.

Дәрәҗә арттыра яки киметә башласа, әйтемнәрдән файдалана. Арттыру алымын мәзәкләр дә ярата. Мәсәлән:

Өч кеше — улы, кызы, әтиләре — начар гына җиңел машиналарын этеп баралар, ди. Улы әтисенә әйтә:

— Әти, бу машина бензинны бик аз яга, дигән иде сатучы, алдамаган икән,— ди.

?! 1. Машина бензинны ни дәрәҗәдә аз яга?

2. Мәзәкне хикәя итеп языгыз. Хикәягезне янга калган бензинга багышлагыз. Бензинга китәсе акчага ниләр алып була? Күбрәк әйбер алып булган саен, машина «яңарак» була.

БОТКА.

Бер әби таеп егылган. Аны Тәнзилә исемле кыз күреп алган. Кыз әбигә ярдәм иткән. Беленнән тотып, аягына бастырган. Хәтта өйләренә кадәр илтеп куйган.

Әби кызга рәхмәт әйткән.

— Тәрбияле, игелекле бала икәнсең. Алла озын гомер бирсен үзеңә. Шундый кызга ни бүләк итсәм дә жәл түгел. Менә сиңа тылсымлы чүлмәк. Өеңә алып кайт та: «Пешер, чүлмәк»,— диген. Чүлмәк шунда ук ботка пешерә башлар. «Ял ит, чүлмәк»,— дисәң, пешерүдән туктар,— дигән.

Тәнзилә, әбигә рәхмәтләр әйтеп, өенә кайткан. Чүлмәкне өстәлгә куйгач: «Пешер, чүлмәк»,— дигән. Чүлмәк, ашыга-ашыга, ботка пешерергә керешкән. Бөтен өй эче тары боткасы чыгарган хуш ис белән тулган. Чүлмәк тагын да пешергән булыр иде дә, кы-

зыбыз аны: «Ял ит, чүлмәк»,— дип туктаткан. Ботканы, әнисе белән телевизор карый-карый, бик тәмләп ашаганнар.

Икенче көнне, кызы юк чакта, Тәнзиләнең әнисе кунак чакырган. Кунаклар җыелгач: «Пешер, чүлмәк»,— дигән. Чүлмәк ялындырып тормаган, пешергән дә пешергән. Ләкин хуҗа аны берничек тә туктата алмаган. Туктату сүзләрен оныткан. Күпме уйласа да, исенә төшерә алмаган. Ә чүлмәк пешергән дә пешергән. Ботка өстәлгә агып төшкән, бөтен идәнне тутырган...

?! Дәвам итегез. Ботка аннан соң кайларга аккан? Арттырыгыз, тагын арттырыгыз... Адәм ышанмаслык дәрәҗәдә арттырган саен, әкият кызыклырак булачак.

Әдипләрне күбрәк кеше сыйфатлары кызыксындыра. Кешенең сыйфатларын санап бетерерлек түгел. Аның яше, буе, авырлыгы, куллары, аяклары, холкы, чәчләре, бармаклары... бар. Әнә шундый бик әһәмиятле сыйфатлары арасыннан әдәбият тагын да әһәмиятлерәкләрен сайлап ала.

Ярдәмгә мохтаҗ кешеләрне кызгана белү — һәркемнең иң гүзәл сыйфаты. Кызгана торган кеше игелекле, шәфкатьле була, ярата ала, менә дигән дус була.

Халык үзенең әйтем-мәкальләрендә кешеләрнең уңай сыйфатларын бик югары дәрәҗәгә күтәреп мактаган.

Даныңны югалтканчы, башыңны югалт, ди мәкаль. «Дан» дигәндә, әлбәттә, кешеләрнең аңа булган хөрмәтен күздә тота.

Осталык дәрәҗәсен арттырып, агачтан сандугач кына ясамый, ди. Җитез кешене, баскан җирдән ут чы-

гара, дип мактый. Көч дәрәҗәсен, басса бакыр изәрлек, типсә тимер өзәрлек, дип арттыра.

?! **1.** Мәкальләрне тагын бер кат укып чыгыгыз. Китабыгызны ябыгыз. Ничәсен исегездә калдырдыгыз? Әйтеп карагыз.

2. Тагын бер тапкыр укыгыз, хәзер күпмесе хәтерегездә калды?

Кешеләрнең яман сыйфатларына багышланган әйтемнәр, мәкальләр, мәзәк, әкиятләр дә күп. Халык, яман сыйфатларның яманлык дәрәҗәсен арттыра-арттыра, ояла белмәүче балаларны көлкегә калдыра. Шундый кешеләрдән гыйбрәт алырга куша.

ӨЧ ТУГАН.

Бер кеше үзенең өч улы белән яшәгән. Уллары үсеп җиткән. Берсеннән-берсе уңган икән. Әтиләре өчесен дә чакырып алган да:

— Илләр гизегез. Кешеләр белән танышыгыз. Нинди дә булса һөнәргә өйрәнеп кайтыгыз. Кайсыгызның һөнәре яхшырак булса, йортны, бөтен байлыгымны шуңа калдырачакмын,— дигән.

Уллары илләр гизәргә чыгып киткән. Чит илләрдә өч ел буе йөргәннәр һәм өчесе дә бер көнне өйләренә кайтып кергәннәр.

— Без юкта исән-сау яшәдеңме, әти? — дигәннәр уллары.

— Исән-сау гына йөрдегезме? Йә, кем ни өйрәнеп кайтты? Сөйләгез,— дигән әтиләре.

— Мин сакал-мыек кырырга өйрәнеп кайттым,— дигән кече улы.

— Мин тимерчелек һөнәренә өйрәндем, әти,— дигән уртанчы улы.

—Мин кылыч белән сугышырга өйрәнеп кайттым,— дигән өлкән улы.

—Бик яхшы булган,— дигән әтиләре.— Инде чәчсакал кыруыгызны, ат дагалавыгызны һәм кылыч белән сугышуыгызны күрәсем килә.

Шулвакыт басудан куян чаба икән.

—Булды бу,— дип кычкырып җибәргән чәч-сакал кырырга өйрәнгән энеләре.

Бер савытка сабын салып, күбеген чыгарган да куянны куа киткән. Куып җиткәч, битләрен, аякларен кырган. Шундый чиста итеп кырган, куян битендә бер йон бөртеген дә калдырмаган.

—Оста кырасың, бер җирен дә кисмәдең, бер йон бөртеген дә калдырмадың,— дип мактаган әтисе.

Әтиләре кече улын мактарга да өлгермәгән, юлда тарантаслы ат күренгән.

—Инде минем осталыкны күр, әти! — дигән уртанчы улы.

Уртанчы агалары тарантасны куып җиткән, җанфәрманга чабып баручы атның дүрт аягыннан да дагаларын йолкып алган да дүртесен дә кире урынына кадаклап куйган.

—Эшеңә күз иярми. Энеңнән аз гына да калышмадың,— дип мактаган әтисе.

—Рөхсәт итсәң, мин дә осталыгымны күрсәтер идем,— дигән өлкән улы.

—Күрсәт, әйдә. Синең осталыгыңны да күрик,— дигән әтиләре.

Ул арада коеп яңгыр ява башлаган. Өлкән агалары кылычын кыныннан суырып алган да баш очында тиз-тиз

болгарга тотынган. Шундый тиз болгаган, яңгырның бер генә тамчысын да башына төшермәгән. Яңгыр көчәйгәннән-көчәя, ә өлкән агалары кылычын аның саен җәһәтрәк уйната икән. Шулай итеп, яңгыр астыннан копкоры чыккан, чөнки тамчыларның һәрберсен кылычы белән читкә бәреп җибәрә торган.

Әтиләре өлкән улының осталыгына сокланып карап торган да:

— Өчегез дә искиткеч осталар икәнсез. Өйне кемгә калдырырга да белмим. Өчегез дә бергә торыгыз,— дигән.

Уллары әтиләре сүзен тыңлаганнар. Шул көннән бирле һаман бергә яшиләр икән.

Бертуган Якоб һәм Вильгельм Гриммнар.

?! 1. Әсәрне вакыйгаларга бүлеп сөйләгез.

2. Осталык дәрәҗәләре сурәтләнгән урыннарны табып, үз сүзләрегез белән сөйләп күрсәтегез.

3. Хәзер үзегез шулай арттырыгыз. Уку тизлегенең югары дәрәҗәсен күрсәтегез.

ЧЫДАМАДЫ.

Булган икән бер бай аучы. Бу бай аучы мактанырга, ялганларга бик ярата икән. Моның ялганына берзаман ышанмас булганнар. Шуннан соң бу бер ярлы аучыга әйбәт кенә бишмәт биргән дә әйткән:

— Мин ни генә әйтсәм дә, син дөресләп торырсың, яме,— дигән.

— Ярар,— дигән теге.

Шулай берзаман кибет янына халык җыелгач, бай аучы тотынган мактанырга.

— Мин, дигән, бервакыт шундый хәлгә очрадым. Бер атуда бер куян белән бер төлке үтердем, дигән. Төлке куян артыннан чаба башлаган гына иде, мин икесенә берьюлы төбәдем дә «шарт!» атып та җибәрдем. Икесе дә мәтәлчек атыл тәгәрәп тә киттеләр,— дигән.

Моңар:

— Юкны сөйлисең, андый хәл буламы соң? — дигәннәр.

Бу бишмәтен биргән теге ярлы аучыга күрсәткән дә:

— Ышанмасагыз, әнә сорагыз, ул да шунда иде,— дигән.

— Дөрес, бик дөрес,— дигән ярлы.

Бай аучы туктамаган, тагын сөйләп киткән.

— Икенче бервакыт шулай үрдәк белән карчыгага тап булдым. Карчыга үрдәкне эләктерим дигәндә генә, мин мылтыкны күтәрәм дә «шарт!» икесе берьюлы аяк төбемә ук төштеләр,— дигән.

Халык ышанмагач, теге ярлы тагын дөресләгән:

— Ялган юк монда, чын,— дигән.

Ә бай һаман сөйли, һаман мактана икән:

— Берзаман һавада киек казлар очып бара иде,— ди икән бу,— шулчакны әллә каян бер бөркет килеп тә чыкты, казлар өстенә аткан ук булып ташлануы да булды. Мин аптырап калмадым, шундук «шарт!» атып җибәрүем булды — җиде каз, бер бөркет килеп төшүе булды. Ышанмасагыз, әнә сорагыз,— ди икән, тегеңә күрсәтеп.

Шунда ярлы аучы чыдамаган, әйткән:

— Мә бишмәтеңне, бай абзый, намусым күтәрми, җыен сөйләгәнең ялган,— дигән.

?! Әкиятнең эчтәлеген бер генә җөмлә белән әйтегез.

КУРКАК КЕШЕ.

Бер кеше урманга барган, ди; урманга барып җиткән чакта, аның борыны сызгыра башлаган, ди. Ул: «Урманда бер-бер кеше сызгыра торгандыр»,— дип уйлаган, ди; тыңлап торган да, ди, кача башлаган, ди. Әзрәк барган да, ди, тыңлап торган, ди, тагы сызгырганны ишетеп качкан, ди. Барган да тагы тыңлап торган, ди. Аннары сызгырган тавыш ишетелми башлагач, агач башына менеп утырган, ди. Сызгырганны тагы ишеткән, ди; ишеткәч, агачтан төшкән дә, ди, йөгереп кайткан, ди.

Кайткач, мич башына менеп утырган да, ди, хатынына әйткән, ди:

— Хатын, безгә кеше килмиме? — дигән, ди. Хатыны әйткән, ди:

— Юк, бер кеше дә килми, — дигән, ди. Шуннан ары борыны сызгырганын белгән дә, ди, бер дә курыкмыйча, өендә тик утырган, ди.

?! Әкият авторы героеның куркаклык дәрәҗәсен «ул искиткеч куркак» дип әйтмәгән. Үз борыны сызгырганнан да курку вакыйгасы белән күрсәткән. Ә сез, урамга чыгарга куркып, көннәр буе өендә тик утыручының ялкаулык дәрәҗәсен күрсәтерлек вакыйга уйлап табыгыз.

«Сабыр төбе — сары алтын» һәм «Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер бирәләр» мәкальләренең мәгънәләрен үз сүзләрегез белән сөйләп аңлатыгыз.

ОСТА СУНАРЧЫ.

(Мюнхгаузен истәлекләре.)

Элек Мюнхгаузен исемле бер кеше яшәгән. Ул адәм ышанмаслык вакыйгалар турында сөйләргә ярат-

кан. Сөйләгәннәренең барысы да үз башыннан кичкән вакыйгалар дип ышандыра торган булган.

Мюнхгаузен вакыйгалары бар да ялганга охшаган, диючеләр булыр. Дисәләр диярләр, ләкин заманында аның тапкырлыгына берәү дә шикләнмәгән. Ул, чыннан да, теләсә нинди кыен хәлдән исән-имин чыгу юлын таба торган аучы булган.

Шундый вакыйгаларның берсе белән танышыйк.

Берзаман Мюнхгаузен, үрдәк атарга дип, Африкага килгән. Кечкенә генә күл янында безнең сунарчыбыз бер көтү симез үрдәк күреп алган.

Мылтыгын кулына алып атыйм гына дигәндә, кинәт куркыныч тавыш ишеткән: р-р-р-р...

Артына әйләнеп караса, якында гына фил хәтле арыслан басып тора икән! Күзләре ашыйм, ашыйм дип ялтырый, тешләре ыржайган!

Мюнхгаузен каушап калмаган. Күз ачып йомганчы мылтыгын төзәп, чакмасына баскан! Ләкин мылтык атмаган! Арыслан бер сикерүдә килеп җиткән, сикергән уңайга аучыбызның мылтыгын кабып йоткан. Мылтык аның аппетитын тагын да арттыра төшкән.

«Ач арысланнан ераграк тору хәерлерәк» дигән нәтиҗәгә килгән Мюнхгаузен һәм артына да әйләнеп карамыйча элдергән! Ләкин арысланнар кешеләрдән тизрәк чабалар. Аучыны ул бик тиз куып җиткән.

Мюнхгаузен бу юлы да каушап калмаган. Кесәсеннән ак яулык чыгарган да арыслан борынына тидерә-тидерә болгарга керешкән. Ак яулыкның килешү билгесе булуын кем белми?! Хәер, арыслан белмәскә мөмкин. Шулай булса да җанварлар патшасы туктап калган.

Батыр сунарчы шул бик аз гына вакыттан файдаланган. Агач башына песи тизлеге белән менеп киткән дә агач очлары өстеннән шылган.

Бер агач очыннан икенчесенә сикерә-сикерә чапканда, ялгыш читкә сикергән һәм баткаклыкка егылып төшкән. Баткаклык баткаклык инде ул, аучыбыз бата башлаган. Бата-бата, баш тиңентен баткан. Инде бетте, батты дигәндә генә, астан уң кулын тартып чыгарган да үз башындагы парикка чытырдап ябышкан. Ярый әле, аучыбыз башына парик ябып йөри торган булган.

Мюнхгаузенның башыннан үткәннәре арасында адәм ышанмаслык хәлләр булган дип кисәткән идек бит. Баткаклык вакыйгасы — шуларның берсе генә.

Мюнхгаузен, бар көчен җыеп, үз чәчен өскә таба тарткан. Шундый итеп тарткан, баткан җиреннән ничек атылып чыкканын үзе дә сизми калган.

Менә ул тагын иреккә чыккан. Тик аның өсте-башы гына пычранып беткән булган. Янәшәдә генә чип-чиста сулы күл бар икән. Мюнхгаузен суга сикергән.

Су астында күзен ачып караса, үрдәкләр йөзеп йөри! «Үрдәкле булу өчен, моннан да уңайрак шартны эзләсәң дә таба алмассың!» дигән нәтиҗәгә килгән сунарчыбыз. Мылтыгы юк-югын, аның каравы өчпочмаклы эшләпәсе бар. Менә ул эшләпәсен басыбрак кигән дә, су өстендә күзләрен генә калдырып, үрдәкләргә таба йөзә башлаган.

Берзаман үрдәкләр бер эшләпәнең, җырлый-җырлый, үзләренә таба йөзеп килүен күргәннәр. Үрдәкләрнең өчпочмаклы эшләпәне гомерләрендә дә күргәннәре юк икән. Кызыксынып, бар да шунда таба йөзә башлаганнар.

Ул да түгел, кинәт су калтырый башлаган. Эшләпәгә таба крокодил йөзеп килүе күренгән. Авызын зур итеп ачкан, үзе өй хәтле икән... Ләкин Мюнхгаузен бу юлы да каушап калмаган — тиз генә суга чумган да үрдәк аякларына ябышкан. Ә үрдәкләргә: «Тизрәк, тизрәк! Ярга таба йөзегез!» — дип кычкырган. Үрдәкләр, кычкырган тавыштан куркып, ярга таба йөзгәннәр. Крокодил артларыннан куа киткән.

Ә ярда Мюнхгаузенны, иреннәрен ялый-ялый, арыслан көтеп тора икән. Берәү булса, һичшиксез, курыккан булыр иде. Ләкин Мюнхгаузен Мюнхгаузен инде ул.

Сунарчыга арттан крокодил, алдан арыслан ташланган. Мюнхгаузен хәленең яманлыгын сизеп алган һәм тиз генә авыр итекләрен салып ташлаган. Йөкләре җиңеләйгәнне генә көтеп утырган үрдәкләр күз ачып йомганчы очып киткәннәр. Ә арыслан, аучыны кабып йотам дип, туп-туры крокодил авызына сикергән.

Тапкыр кешеләр өчен үтә алмаслык киртәләр була алмавын күрдегезме инде?

Мюнхгаузенны дөньяда иң тапкыр кеше дип юкка гына сөйләмиләр шул.

?! 1. Хикәядә берничә вакыйга бар. Шул вакыйгаларны берәмберәм сөйләп чыгыгыз.

2. Һәркайсына исем бирегез.

3. Мюнхгаузен беркадәр арттырып сөйләгән урыннарны табыгыз.

4. Әгәр Мюнхгаузен, дәресегезгә кереп, үзенең башыннан үткәннәрне сөйләсә, мөгаен, рәхәтләнеп тыңлар идегез. Ни өчен яратып тыңлар идегез, алдап сөйли бит ул?

БҮРЕК.

Бүрек тегүчегә берәү сарык тиресе алып килә.

— Шушы тиредән миңа бүрек тегеп бир әле,— ди.

— Була ул,— ди оста.

Тире иясе, өенә кайта-кайта:

— Тире шактый зур бит. Ике бүрек тегәргә җитәргә тиеш,— дип уйлана.

Шулай дип уйлый да оста янына әйләнеп кайта.

— Әйт әле, дус кеше, бу тирене ике бүреккә җиткерә алмассыңмы? — дип сорый.

— Җиткерә алам, нигә җиткермәскә? — дип җавап бирә оста.

— Алайса, ике бүрек тек,— ди тектерүче һәм кайтып китә.

Бераз киткәч, тагын уйга бата һәм тагын оста янына әйләнеп кайта.

— Теге тиредән өч бүрек тегә алмассыңмы? — дип сорый...

?! 1. Әкиятне дәвам итегез һәм тәмамлагыз. Оста аңа ни дип җавап бирә? Аннан соң тектерүче ни эшли?

2. Тегелгән бүрекләрен алгач, тектерүче шатланамы?

3. Әкияттә нинди сыйфат дәрәҗәсе арттырыла?

ҖИТЕЗЛӘР.

Ике бала тары басуына китә. Яңгырява башлый. Балаларның берсе тары кәрзинен башына куеп бара. Яңгыр җирне чылатып тайгак итә. Баланың аягы тая. Баш өстендәге кәрзин, авышып, җиргә төшә башлый. Үзләренең өйләре янынннан узган арада, бала тәрәзәдән үрелеп пычак ала. Юлда үскән тал ботакларын

кисеп җиргә җәя, палас итеп бәйли. Кәрзиннән коелган тары шул тал-палас өстенә төшә. Бала паласка коелган тарысын кәрзиненә сала да:

— Палас ясап, аяк астына җәяргә кирәклеге башыма килмәсә, тарысыз калган булыр идем, — ди.

Балаларның икенчесе унбиш читлеккә ябылган кырык чеби алып бара. Бераз киткәч, саф һава сулап чүпләнсеннәр дип, чебиләрен читлектән чыгара. Ул арада бер тилгән, уктай атылып, чебиләр өстенә төшә башлый. Бала чебиләрен тиз генә җыя. Һәркайсын үз читлегенә ябып куя һәм тилгәнне аягыннан эләктереп ала.

— Ә син чеби урлаган өчен нинди җәза бирелүен беләсеңме? Белмәсәң, менә хәзер белерсең, — ди.

?!
1. Әкиятне ике өлешкә бүлегез.
2. Балаларның җитезлек дәрәҗәсе турында сөйләгез.

ТИМИ ТЕЛ ОЧЫНА ДА.

Кыза башлый да
Күзем,
Бетә башлый да
Түзем,
Кызулый башлыйм
Үзем!

Каян килә бу тизлек,
Бу тизлек,
Бу җитезлек?

Күзгә күренеп кими,
Тел очына да тими —
Шоколад та тиз бетә,
Лимонад та тиз бетә,

Варенье да тиз бетә,
Печенье да тиз бетә...

Кими алар — күземне
Ачып йомган тизлектә.
Әһә, белдем!
Ашыгучы
Мин түгел, алар икән.
Мин — ярый инде, алар
Ник ашыгалар икән?

Роберт Миңнуллин.

?! 1. Автор героеның нинди сыйфатын арттырып күрсәткән?
2. Әсәр герое үзе турында үзенчә сөйли. Ә сез аның турында ул сөйләгәннәрне үзегезчә әйтеп бирегез.

ГУЛЛИВЕР СӘЯХӘТЕ.

(Әсәр кыскартып бирелә.)

Гулливер исемле табиб сәяхәт кылырга ярата. Аның башка җирләрдәге кешеләрнең ничек яшәүләрен беләсе килә.

Бу юлы ерак китә алмый. Төньяк диңгезендә, каты җил чыгып, кораблары бата. Гулливер берүзе исән кала. Йөзә-йөзә бик арый, алай да аяклары төпкә

тигәнче йөзә дә йөзә. Ярга аяк басу белән, чалкан ятып йокыга тала. Иртә белән уянып киткәч белә: ул бик кечкенә кешеләр яши торган Лилипутия иленә йөзеп чыккан икән. Бу илнең кешеләре өч бармак озынлыкта гына икән. Шул кешеләр аны неп-нечкә җепләр белән аркылы-торкылы бәйләп, җеп очларын җиргә каккан чөйләргә чорнап куйганнар икән.

Гулливер алар телен, лилипутлар аның телен аңламый. Гулливер җепләрен өзә. Ләкин торып утырмый, чөнки лилипутлар ук ата башлыйлар. Энәдән дә кечкенәрәк йөзләп уклары, зыян китермәсәләр дә, чеметтереп кадалалар. Шуңа күрә Гулливер ятып торуны хуп күрә.

Бераздан ул озын баскычлар куеп өстенә менгән лилипутлардан, кулларын авызына китереп, ашарга сорый.

Лилипутлар ымны аңлыйлар. Ашарга китерәләр. Гулливерның як-ягына берничә озын баскыч сөяп куялар. Чирек сәгать үткәндерме-юктырмы, йөзләрчә кеше, ашамлык салынган кәрзиннәрен көч-хәл белән күтәреп, өскә менә башлыйлар...

Гулливер кыздырылган биш үгез, сигез каклаган сарык, унтугыз ысланган дуңгыз, ике йөзләп тавык һәм каз ашый. Нәни кешеләр моны күреп ах итәләр.

Ашаганнан соң, Гулливер тагын ятып йоклый. Аны йокы даруы салып сыйлаганнар икән.

Лилипутиядәге иң биек агачлар бездәге карлыган куагы хәтле генә, ә иң биек йортлары бездәге өстәлдән дә тәбәнәгрәк икән. Гулливер кебек дәү кешене моңа кадәр берсенең дә күргәне булмаган.

Патша Гулливерны башкалага китерергә куша.

Император кушуы буенча, биш йөз балта остасы егерме ике тәгәрмәчле арба ясыйлар. Арбаны Гулливер янына китереп куялар.

Иң куәтле тугыз йөз пәһлеван, сәгать буе тырышып, Гулливерны ярты бармак биеклеге күтәрәләр, өч сәгать маташканнан соң гына, арбага салалар.

Песи баласы хәтле мең ярым иң көчле ат, ун рәткә җигелеп, Гулливерны башкалага көне буе тарталар.

Шәһәр капкасы янында гына ике манаралы ташландык йорт бар икән. Гулливерны шул йорт янына китерәләр.

Бу йорт Лилипутиянең иң биек йорты икән. Аның ишеге хәтта Гулливер кебек дәү кеше дә шуышып керә алырлык биек икән. Патша аны шушы бинада яшәтергә ниятләгән.

Гулливерның аягын туксан бер чылбыр белән тышаулап, бер очын бинага туксан бер йозак белән бикләп куялар.

Гулливер, берәрсе ялгыш аяк астында калмагае дип, сак кына аягына баса һәм як ягына күз ташлый. Аның шушындый матур илне бервакытта да күргәне булмый.

Гулливер янына халык җыела. Аны күрү өчен, хәтта патша үзе дә килә. Гулливер патшага голланд, латин, грек, француз, испан, итальян, төрек телләрендә үзенең кем булуын әйтеп карый. Ләкин патша ул телләрне белми, ә Гулливер патша әйткәннең бер сүзен дә аңламый.

Гулливер, бәйдәге солдат кебек, өе янында утыруын дәвам итә. Аны күрергә, ким дигәндә, өч йөз мең лилипут җыела. Ә малайлар аңа ук, таш атып кылана башлыйлар. Укларның берсе Гулливерның муенын тырнап үтә, ә берсе әз генә күзенә тими кала.

Лилипутиядә андый усал балаларга каты җәза бирәләр икән. Гулливерны саклаган солдатлар алты усалны шунда ук эләктереп алалар да, кул-аякларын

бәйләп, сөңгеләре белән төрткәли-төрткәли Тау-кеше (монда Гулливерга шундый исем бирәләр) янына китерәләр. Лилипутиядә шуннан да катырак җәзаны бирәүгә дә биргәннәре булмый.

Гулливер усал балаларны иелеп кулына ала да пиджак кесәсенә сала. Ә берсен кулында калдыра. Аны күзенә якынрак китереп карый: лилипут Гулливер бармагына чытырдатып ябыша. Куркуыннан елый башлый. Гулливер елмая да кесәсеннән пәкесен чыгара. Аның теше белән пәкесен күргәч, лилипут шәрран ярып акыра башлый. Шау-гөр килгән халык куркудан кинәт шып була.

Ә Гулливер малай кулларын бәйләгән бауларны пәкесе белән кисә дә үзен җиргә бастыра. Аннары кесәсендә чәбәләнгән башкаларын да шулай азат итә.

—Яшәсен Тау-кеше! — дип шау килә җыелган халык.

Ә патша сараенда министрлар Гулливерның язмышын хәл итәләр.

Ул бик көчле, шуңа күрә куркыныч. Өстәвенә мең дә җиде йөз егерме сигез кешене туйганчы ашатырлык ипи белән итне берүзе ашап бетерә. Шуның өчен аны үтерергә кирәк дигән карарга киләләр.

Ләкин кинәт ишек ачылып китә дә, патша бүлмәсенә ике офицер керә һәм Гулливерның алты кешене гафу итүен сөйли.

Шәфкатьлелеге турында ишеткәч, патша әсирен исән калдырырга карар кыла.

Гулливер тоткынлыкта ярты ел яши.

Илнең иң танылган алты галиме аңа лилипутлар телен өйрәтә. Ике ай эчендә Гулливер бу ил кешеләре белән шактый иркен сөйләшә башлый.

Гулливер иң элек «Олыларның олысы бөек патша, туган илемә җибәрүегезне үтенеп сорыйм» җөмләсен өйрәнә. Монда яшәгәндә аның иң яратып кабатлаган җөмләсе шул була. Ләкин патша аның үтенечен үтәргә ашыкмый.

Тора-бара лилипутлар Гулливердан курыкмый башлыйлар. Кичләрен җиргә яткан Тау-кешенең чәче арасында качышлы уйнарга яраталар. Хәзер мондагы атлар да ят кешене күреп өрекмиләр.

Гулливер әле һаман чылбырга бәйләнгән килеш яши бирә. Күңелсез булмасын дип, үзенә өстәл белән урындык һәм карават ясый. Бу эш өчен аңа меңгә якын иң озын һәм калын агачлар китереп өяләр.

Илнең иң оста тегүчеләре дүрт матрас тегеп бирәләр. Ул матрасларны тегү өчен, алты йөз лилипут матрасын кушарга кирәк була. Юрган белән япмасын да шулай тегәләр.

Гулливерны көнгә өч тапкыр ашатыр өчен, өч йөз пешекче тырыша. Аш-су пешерү бүлмәсе бөтен юл буена сузыла. Уң якны аш-су бүлмәсе били, сул якта пешекчеләр гаиләсе өчен йортлар төзелә.

?! Әсәрнең беренче өлешендә автор безне Гулливер белән таныштыра. Аннан соң аның әсирлеккә төшүе турында яза. Шуңа күрә беренче өлешкә «Сәяхәт яратучы», ә икенчесенә «Әсир төшү» дип исем бирә алабыз. Шуннан соң автор нәрсә турында яза?

Богаудан коткарыгыз дип, көн дә үтенә торгач, ниһаять, Гулливерны азат итәләр. Азат итү кәгазендә император мондый сүзләр яза: «Әгәр дә Тау-кеше безнең рөхсәттән башка Лилипутия илен ташлап китмәскә, олы юлдан гына йөрергә, кеше таптамасын өчен, аяк

астына карап йөрергә, күршедәге ил белән сугышканда, безнең якта сугышырга, төзүчеләргә иң авыр ташларны күтәрергә, урман чистартканда, агачларны тамырлары белән йолкырга, тирән коелар казырга, юлларны тап-тап тигезләргә, дәүләтне әйләнеп чыгарга һәм ничә адым булуын хәбәр итәргә сүз бирсә, аны дәүләт хисабына туйдырырга һәм азат итәргә боерам».

Гулливер барлык шартларны үтәргә риза була.

Аяклары чылбырдан ычкынгач, Гулливер шәһәр карарга чыгып китә. Йортларны атлап чыга-чыга, патша сараена килеп җитә. Ә патша сараенда күрше утрау белән сугыш турында киңәшмә үткәрәләр икән.

Гулливер, әлбәттә, утырыш залына сыймый. Ләкин тәрәзәдән генерал әйткән сүзләрне ишетеп тора.

— Ике бөек ил ни өчен сугыша? — дип сорый Гулливер, түземлеген югалтып.

Аңа болай дип аңлаталар.

— Йөз ел элек хәзерге патшаның бабасы, ул чакта патша улы, иртән йомырка ашарга утыра. Йомыркасын тупыйк башыннан вата. Ләкин кабыгына бармагын кисеп каната.

Лилипутия патшасы шул көнне дәһшәтле фәрман чыгара. Фәрманы белән бөтен ил халкына йомырканы тупыйк башыннан ватып ашамаска куша. Бу фәрманны үтәмәүчеләрне үлем көтә, дип тә өсти.

Боерык белән танышкач, Лилипутия халкы ике дошман төркемгә аерыла. Төркемнең берсе йомырканы тупыйк яктан ватып ашау ягында, ә икенчесе очлы ягыннан ватып ашау ягында була.

Йомырканы тупыйк башыннан ватып ашарга теләүчеләр патша фәрманына буйсынмыйлар һәм Блефуску дип аталган утрауга качалар.

Лилипутлар патшасы Блефуску императорына качкыннарны җәзаларга куша. Ләкин император патша фәрманын үтәми. Качкыннарга хәтта эш бирә — аларны гаскәренә хезмәткә ала.

Шул вакыттан бирле бу ике ил арасында сугыш туктап тормый.

Безнең иң куәтле патшабыз сездән ярдәм көтә, Тау-кеше, — дип, сүзен тәмамлый сугыш сәбәбен аңлатучы лилипут.

Гулливер сугышның сәбәбен аңлап бетермәсә дә ризалаша, чөнки патша куйган таләпләрне үтәргә тиеш була.

Блефуску илен Лилипутия иленнән шактый киң су бугазы аерып тора икән. Гулливер, ярга килеп, үзенең зурайтып күрсәтә торган торбасыннан карый һәм аргы якта ничә хәрби кораб барлыгын белә. Патша янына кайтып, озын бау, кораблар санынча илле ыргак сорый. Бер сәгать үтүгә, аңа сораган бауны һәм бәйләү энәсенә охшаган тимерләр китереп аударалар.

Гулливер төн буена бау ишә, тимерчыбыкларны бөгеп, ыргаклар ясый.

Ә таң беленер-беленмәс, бауны җилкәсенә элеп, яр буена китә. Анда аяк киемен, оегын, бишмәтен сала һәм суга кереп китә.

Су төбеннән атлап, тирән җирендә йөзә-йөзә, ярты сәгать эчендә Блефуску флоты янына килеп җитә.

Гулливерның киң җилкәсен һәм башын күргәч, мондагы матрослар:

— Утрау йөзеп килә, утрау! — дип кычкыралар.

Гулливер кулын алга сузгач, котлары очып, бар да суга сикерәләр.

Гулливер корабларны ыргагына элэктерэ дэ, иллесен дэ бер кулы белэн тартып, каршы якка йөзеп китэ.

Лилипутия халкы, еракта күп санлы кораб күргэч, башта куркып кала. Дошман һөҗүм итэ, дип уйлый. Лэкин Гулливерны таныгач, шатлыклары эчлэренэ сыймый.

Ярга аяк басу белэн, Гулливерга илнең иң югары бүлэген — өч тасма бирэлэр. Үзлэре билгэ буып йөри торган зэңгэр, кызыл һэм яшел тасмаларны Гулливер бармагына урап куя.

Икенче көнне патша Тау-кешегэ тагын бер эш йөкли. «Блефуску халкы балык тоту һэм сэүдэ итү белэн генэ яши. Калган корабларын алып кайтсаң, алар бар да Лилипутия иленең колы булачак. Шуннан соң бар да йомырканы очлы ягыннан гына ашарга тиеш булачаклар», — ди.

Лэкин Гулливер бу эштэн баш тарта. «Кол булып яшэүнең авырлыгын мин үз җилкэмдэ татыдым, шуңа күрэ халык хэтле халыкны кол итэ алмыйм», — дип җавап бирэ.

Шул көннэн башлап, ул патша өчен дошманга эйлэнэ. Ә беркөнне яшерен җыелышларында патша үзенең вэзир, генераллары белэн Гулливерны сукырайтырга карар кылалар. Бу хэбэрне аңа дуслары төнлэ килеп эйтэлэр. Шул төнне үк Гулливер Блефуску утравына таба йөзеп китэ...

Джонатан Свифт.

?! 1. Эсэрне башта өлешлэргэ бүлеп чыгыгыз. Аннары шул план буенча эсэрдэге вакыйгаларны тулы килеш сөйлэгез.

2. Бик нык арттырылган урыннар турында эйтегез.

Әсәр һәм аның авторы турында.

Гулливер сәяхәтләре турындагы әсәрне инглиз язучысы Джонатан Свифт моннан ике йөз ел элек иҗат иткән. Китап бик күптән язылса да, аны бөтен дөньяда хәзер дә яратып укыйлар.

Кызык булмаса, сезне аның язмышы борчымас иде. «Гулливер Туган иленә кайтып балаларын күрә алганмы?» соравына җавап бирик.

Кайтып җитә алган. Балаларын да күргән. Бар да бик шатланганнар. Ә ничек кайтып җиткән? Анысын китапны тулы килеш укыгач белерсез.

Китап кызык, чөнки без дөньяда була алмый торган ил һәм анда яши торган бармак башы хәтле генә кешеләр белән очрашабыз. Аларның эшчәнлегенә сокланабыз. Араларындагы мактанчыклардан, ахмаклардан көләбез.

Автор кешенең мин-минлек сыйфатын арттырып язган, чөнки мактанчыкларның, лилипутия патшасы кебек, көлке, надан кешеләр булуын бик яхшы белгән.

Әсәр дәреслектә бик нык кыскартылып басылды. Тулы килеш укысагыз, ул тагын да кызыклырак булачак.

?! Китапның дәвамы да бар. Сез укыган беренче өлешенә автор «Гулливер лилипутлар илендә» дип исем куйган. Шулай булгач, икенче китап исеме нинди булырга мөмкин? Икенче китап исемен уйлап табыгыз.

ҖИЗНИ ӘКИЯТЕ.

Һич арттырмыйм, чын әгәр,
Иртәдән кичкә кадәр

Әкият тыңлый Бәдәр.
Әбидән дә сөйләтә,
Бабайдан да сөйләтә,
Әтидән дә сөйләтә,
Абыйдан да сөйләтә,
Әнидән дә сөйләтә.
Сөйлә, сөйлә тагын, ди,
Сөйлә озынрагын, ди.

«Шүрәле»не, «Шомбай»ны,
«Кәҗә белән Сарык»ны,
«Бүре белән Кәҗә»не,
«Аю белән Төлке»не,
«Төлке белән Торна»ны
Инде ничә тыңлады.
Сөйлә, сөйлә тагын, ди,
Сөйлә озынрагын, ди.

Кунакка килгәч апа,
Аны да аптырата.
Апам сөйләп тә карый,
Сөйли-сөйли дә арый:
— Йә инде, чама бел, ди,
Мин радио түгел,— ди.
Бәдәр, тагын, тагын, ди,
Сөйлә озынрагын, ди.

Тыңлап тора да җизни:
— Үзем сөйлим,— ди, түзми:
«Булган, ди, бер Саескан,
Атна очкан, ай очкан.
Һәм очып барган төштән
Асфальтка килеп төшкән.

Асфальт — йомшак сумала,
Койрык ябышып кала!
Койрыгын ала —
Томшык ябыша.
Томшыгын ала —
Койрык ябыша.

Койрыгын ала —
Томшык ябыша.

Томшыгын алса,
Койрык ябыша.
Койрыгын ала —
Томшык ябыша...»
Әллә Бәдәр дә
Тыңлап бер туйды:
«Җитте...» — дип куйды,
Күзләрен йомды.
Кем дә кем әгәр
Белмәсә чама,
Җизни әкиятен
Сөйләгез аңа.

Шәүкәт Галиев.

71 **1.** Әкият тыңларга яратучы кызның бер начар сыйфаты бар. Ул чама белми. Башкаларга мәшәкать тудыручыларга «әдәпсез» диләр. Шигырьдәге кыз да шундый. Ул, әкият сөйләтеп, өлкәннәрне аптырата. Кыз әдәпсез, ә җизни нинди кеше?

2. Шигырьне ике өлешкә бүлегез.

3. Шигырьдә автор катнашкан урынны табыгыз.

Кешенең күңел дөньясы.

Нәрсә ул хис? Җавапны бергәләп искә төшерик әле.

Сез, иртән торып, мәктәпкә киттегез, ди. Юлда шыңшып утыручы иясез көчек күрсәгез, ни эшләр идегез? Мөгаен, ач, күшеккән көчекне кызганып, сумкагызда ипи булса, ипи дә сындырып бирер идегез.

Ярдәмгә мохтаҗларны кызгану — хис. Бик матур хис.

Тагын ярты елдан соң шул ук юлда шул ук көчекне танып аласыз. Хәзер көчек үскән, матурайган. Иясе янында уйный-уйный бара. Бу юлы, мөгаен, мескен көчек иясен тапкан, дип шатланыр идегез.

Башкаларның бәхетенә шатлана белү дә — хис. Ул да — бик матур хис.

Шул чакта өйгә алып кайткан булсам, нинди матур этем булыр иде дип, үкенеп тә куярсыз.

Хатаңны танып үкенү дә — хис. Күңелсез хис.

Кызгану, шатлану, үкенү, хәсрәтләнү, курку, оялу, ачу килү, үпкәләү ... — барысы да хис.

Кешеләрнең яратуы, нәфрәте, хәсрәте, оялуы, шатлыгы, үкенече, үпкәләве — барысы да аның күңел дөньясы. Алар тормыштагы предметлар кебек хәрәкәтләнәләр: хәсрәт шатлыкка, шатлык үкенечкә, үкенеч кабат хәсрәткә алмашына.

Рәсем дәресенә төсле карандашларыгызны онытып килдегез, ди. Хәсрәтегез зур булмый булуын, алай

да борчыласыз. Үкенәсез. Күршегез үз карандашларын биреп торгач, борчуыгыз шатлыкка әйләнә, аңа карата ихтирамыгыз арта. Өегезгә кайткач, әтиегезнең сезгә велосипед алып кайтуын белдегез, ди. Тагын шатланасыз, ничек кенә шатланасыз әле! Нәтиҗә ясыйк: шатлыкның кечкенәсе дә, зурысы да була. Менә шундый үсешкә **шатлык дәрәҗәсе** диләр. Шатлык дәрәҗәләре шулхәтле күп, аларның хәтта исемнәре дә юк. Шуңа күрә язучылар, шатлыкны күрсәтү өчен, шатланган кешенең халәтен күрсәтергә тиеш булалар. Мәсәлән, шатлыктан башы күккә тиде, диләр. Монысы иң югары дәрәҗә була. Ничек сурәтләү язучының осталыгына бәйле.

Шатлыкның тагын бер бик җитди үзенчәлеге бар: ул күренми дә, ишетелми дә, тавышланмый да. Ә үзе бар. Шулай булгач, аның эчтәлеген ничек беләбез? Сәбәбеннән беләбез. Сәбәпсез шатлык та, хәсрәт тә, үкенеч тә — берсе дә тумый.

Хиснең дәрәҗәсе.

Әйбер сыйфатлары кебек, хис тә дәрәҗәле булырга ярата.

Мәсәлән, шатлык бик зур булмаса, «күңел күтәрелде» диләр. Шатлык хисе артса, «кош токандай» буласың. Ә шатлыкның иң югары дәрәҗәсен аңлатып бирү өчен, «күккә сикердем» яки «шатлыгым эчемә сыймый» әйтемнәрен искә төшерәсең.

Хис хәрәкәтләнергә ярата, бер генә минут та тик тормый. Шатлык кинәт үкенеч белән алышына, үкенергә өлгермисең, горурлык хисе чолгап алуын сизми дә каласың.

Безнең әби-бабайларыбыз чыгарган җырлар арасында хиснең бик югары дәрәҗәсен күрсәткәннәре бик күп. Аларның һәрберсендә мәхәббәт хисенең дәрәҗәсен җырлап бирү өчен башка сүзләр, башка сурәтләр табылган. Мәсәлән:

Ай югары, ай югары,
Ай югары салкынга;
Агач булса янар иде
Эчемдәге ялкынга.

Гөлбакчада гөлләрем күп,
Арасында бадьян[1] юк;
Бергә үстек, бергә укыдык,
Сагынмаган көнем юк.

Ай яктысы бик якты да,
Көн яктысы күк түгел;
Башка дусларым юк түгел,
Син дускаем күк түгел.

Җырчылар хәсрәтләренең зурлыгына зарланганнар. Ләкин шуның артыннан ук:

Урман артларында күлләр булыр,
Күл янында гөлләр дә булыр;
Гөл саргая диеп, без саргаймыйк,
Бәлки, рәхәт көннәр дә булыр, —

дип, үзләрен юатканнар. Хәсрәт хисе тиз арада өмет хисенә әверелгән.

---

[1] Бадьян — анис гөленең бер төре. Бик матур, исле чәчәк.

МӘКТӘПКӘ.

Кечкенә дусларның
Шатлыгы шундый зур.
Йөзендә аларның
Туктаусыз уйный нур.

Сумкалар чайкала
Шатлыктан, әлбәттә.
Дөньяның яшьлеге
Ашыга мәктәпкә.

Зыя Мансур.

?! Балалар шатлана. Автор шатлык дәрәҗәсен «шатлыгы шундый зур» дип аңлаткан. Аның зурлыгын ике урында күрсәтеп тә биргән. Ничек сурәтләвен аңлатыгыз.

СУСЫЗ ЕЛГА.

Безнең авылның нәкъ уртасыннан зур гына сусыз елга ярып үтә. Җәй урталарына кадәр аның төбеннән атлап кына чыгарлык кечкенә инеш тә чылтырап агып утыра. Ләкин җәйге чилләләрдә ул бөтенләй кибә, елга төбен үги ана яфрагы, бака яфрагы, каз үләне баса. Колач җитмәслек юан тал төпләрендә куак күк зәһәр кычыткан, эшләпә ясап кияплек әрекмәннәр үсә, кәҗә сакалы, балтырган, сусыл көпшә дә җыярга була. Зәп-зәңгәр кыңгырау чәчәк, әфлисун төсендәге әби башмагы чәчәге, алсу дегет чәчәге күзләрне иркәләп, үзенә тартып тора. Яр буйларында тукранбаш, кетүче сумка-

сы, өчьяфрак үсә, кузгалак, акбаш бик уңа, җир җиләге дә күп була.

Рафаил Төхфәтуллин.

?! Бер кат укыгач, китабыгызны ябыгыз. Сусыз елганың ике халәтен бик кыска итеп дәфтәрегезгә языгыз. Текстны тагын бер кат укыгыз. Елга сыйфатларын мөмкин кадәр тулы итеп күз алдына китерегез һәм дәфтәрегезгә языгыз.

АК ГӨМБӘ.

— Иртәгә иртүк ак гөмбәгә барабыз. Кәрзин, пычагыңны әзерләп куй. Кулыңа бияләй ал. Җиңле күлмәк ки, башыңа кипке эләргә онытма — урманда черки таламас,— диде күршедәге Миңсылу әби.

Күңел күтәрелеп китте. Миңсылу әби урманга барганда теләсә кемне ияртми. Җитмәсә, бүген ак гөмбә үсә торган урынга барабыз, дип шатландырды.

Ак гөмбә ак гөмбә инде ул. Әтисе белән көн дә гөмбәгә йөри торган Садрый, бер генә ак гөмбә тапса да, очраган берәүгә шул гөмбәсен күрсәтә-күрсәтә, мактанып кайта.

Беренче әтәч кычкырып җибәрү белән сикереп тордым. Кәрзинне эләктереп, Миңсылу әбиләр капкасы янына чыгып бастым.

Таң ата. Нинди матур безнең авыл таңы! Безнең авыл таңны ашыкмыйча-кабаланмыйча гына аттыра икән. Менә ул кояшның өске бөҗрасын гына күрсәтеп куйды. Бөҗра кояш шул яктагы болытларны ялт иттерде. Аннары авыл кояшны югарырак күтәрде дә болыт-

лар эченә яшереп торды. Ап-ак болытчык эченнән чыкканда, кояш трактор тәгәрмәче кебек зур һәм туп-түгәрәк иде. Менә ул миңа туп-туры карап елмайды, көлде, неп-нечкә озын кулчыклары белән башымнан сыйпады.

Таң атуын моңа кадәр дә күргәнем бар иде. Ләкин нәкъ менә шул таңда күргән матурлык әле дә күз алдымда.

Миңсылу әби озак көттермәде. Без урманның Кара урман дип аталган ягына карап юл тоттык.

Күрше әби гөмбәле урыннарны үзенең биш бармагы кебек белә.

— Монда, вакыты җиткәч, таш гөмбә үсә. Ә менә монда каен гөмбәсе була, нарат гөмбәсен яшь наратлыктан эзләргә кирәк,— дип, юл буе сөйләнеп барды. Биек үлән баскан чыклы юлдан бара торгач, каенлыкка килеп чыктык.

— Миннән ерак китмә, адашырсың,— диде әби. Бераз бару белән, бөгелеп, гөмбә кисеп алды да миңа сузды.

— Ак гөмбә — менә шушы ул. Яулыгы көрән, ә аягы ак булыр,— диде.

Тотып карадым. Таш кебек каты, кояш кебек нурлы бик матур гөмбә!

Үз гөмбәмне мин шактый йөргәч кенә таптым.

Менә ул мине яраткан ак гөмбә! Беләктәй юан, ап-ак аягында басып тора. Менә ул гөмбәләр гөмбәсе! Көрәшчедәй таза, лачындай горур, матурлыгына сокланып, исен иснәп туймаслык гөмбә!

Шатлыгымнан биеп китәрдәй булдым. Кисәргә кызганып, мин аңа шактый озак карап тордым. Башка гөмбәләрне күргәнем бар, аларның бер ише яфрак астына качкан була. Бер ише агулы гөмбәгә охшый. Бер ише хәтта, кеше күрмәсен дип, агачка менеп үсә. Ә ак гөмбә качмый. Әллә каян күренеп тора.

—Менә мин! Карагыз, сокланыгыз, төптән кисеп, тамырымны кузгатмыйча алып китсәгез, тагын үсәрмен, тагын алып китәрсез! Мин сезнең өчен үстем,— ди.

Беренчесен кәрзинемә салуга, шунда ук икенчесе, өченчесе очрады. Очраган саен, шатлыгым арта, кәрзин авырайган саен сөенеп туя алмыйм.

Менә мин авыл урамыннан кайтып киләм. Кәрзинем тулы ак гөмбә. Күңелем тулы ак хисләр!

Мин, Садрый кебек, очраган бер кешегә гөмбә күрсәтмим. Минем гөмбәләрем үзләре күренеп тора. Мин Садрый кебек мактанмыйм. Горурланып кайтам.

—Булдыргансың,— дип мактады мине Миңсылу әби. Күп сөйләшми торган кешенең бер сүзе ни тора. Мин Миңсылу әби мактавына да сөенәм. Өйгә кергәч, әниемне сөендерәм дип тә сөенәм...

Шул көннән соң мин туган авылымны тагын да ныграк яраттым. Ул мине таңына сокланырга өйрәтте. Урмандагы каен яфраклары белән эсседән саклады, черкиләр көтүен өстереп, чыдамлыгымны сынады. Күршедәге аз сүзле мәрхәмәтле әби белән дуслаштырды. Берсеннән-берсе матуррак ак гөмбәләр бүләк итте.

Шул көннән соң мин гөмбәгә Миңсылу әби белән дә баргаладым, дусларым белән дә, үзем генә дә йөрдем. Ләкин күп еллар үтүенә карамастан, шушы сөенечемне төкми-чәчми хәтеремдә саклыйм. Базарда ак гөмбә күрү белән, кылт итеп үзем тапкан батыр гөмбәләр исемә төшә дә, хәтердәге сөенечем уяна. Иң беренче ак гөмбәм күз алдыма килеп баса. Аннан соң икенчесе, өченчесе... Шул хисләрнең барысы-барысы хәтеремдә саклана. Ул хисләргә яңалары өстәлде. Алар арасында борчулылары да, үкенеч кебек искә төшерәсе килмәгәннәре дә өелделәр. Хисләремнең өске катламы

арасында күрәннәре дә бар, билгеле. Ләкин аста өем-өем ап-ак хисләр, балачак хисләре минут саен өскә калкып чыгарга чират көтеп яталар. Әз генә сәбәбе чыкты исә, ялт итеп өскә калкып чыгалар да мине, күз ачып йомганчы, балачак урманнарына илтеп куялар.

Хәзер яхшы беләм: **кешенең күңеле** ул хәтердәге хисләр тупланмасы икән. Күңеленә тамыр җәйгән ак хисләр күбрәк булган саен, кеше бәхетлерәк була икән. Рәхмәт сиңа, туган авылым! Рәхмәт сиңа, Миңсылу әби! Рәхмәт сиңа, ак гөмбә!

Альберт Гатуф.

?! 1. Әсәрне өлешләргә бүлегез. Һәркайсына исем уйлап табыгыз.

2. Лирик герой шатлыгының арта баруы турында сөйләгез.

БЕЗНЕ САГЫНЫП.

Әй тышта яңгыр коя!
Урамнар елап тора:
Елый яфрак-үләннәр,
Стеналар, түбәләр,
Елый кояш һәм болыт,
Яшьләр тама: тып-тып-тып.

Тышта яңгыр булганга
Чыгалмыйбыз урамга.
Безне сагынып, урамнар
Шулай елап торалар.

Нурия Измайлова.

?! 1. Шигырьдә авторның безнең белән сөйләшкән урынын табыгыз.

2. Автор нинди хис турында яза? Ул хиснең югары дәрәҗәсен ничек күрсәтә?

3. Хис ияләрен әйтегез.

СӨБХАНАЛЛА!

Гармунчы гармун ала.
Каешын иңгә сала.
Алларында туктап кала
Күбәләктәй кыз бала.

Чәчәкле итәкләре,
Чигүле читекләре,
Сөрмәледер күзләре,
Сөйкемледер йөзләре.

Бер сыздыруы җитә,
Талпынып биеп китә —
Җитездер аяклары,
Алмадай яңаклары.
Тыпыр-тыпыр биидер,
Аягы җиргә тимидер.

Сихерләнгәндәй халык
Карый аңа, таң калып:
— Абау ла, сөбханалла,
Фәрештә кебек бала!..

Резеда Вәлиева.

?! Хис дәрәҗәсе күрсәтелгән урынны табыгыз.

Хиснең сәбәбе.

Ә хис ничек туа?

Сез кичә дәрестә «биш»ле алдыгыз, ди. Укытучының шундый югары бәясенә ничек шатланмыйсың. Башкаларга сиздермәскә тырышып шатланасың. Шатлыкның сәбәбе «биш»ле билгесе булды. Ә «биш»ле билгесе алуның сәбәбе дәресне өйдә өйрәнеп килү иде.

?! 1. Өйдә дәресне әзерләү сәбәбен әйтегез.

2. «Ак гөмбә» хикәясендәге гөмбәче малай хисенең сәбәпләрен искә төшерегез.

ЭШ.

Һәр шатлыкның бер сәбәбе була:
йә кемнәндер бүләк аласың,
йә укыйсың берәр кызык китап,
йә урманда гөмбә табасың.

Бүген иртән мин бакчага чыктым,
түтәлләрнең чүбен йолыктым:
йолыкмасам,
бу чүп
кыярларны
басып китәр диеп курыктым.

Баш очымда — кояш...
Тирләп беттем,
күлмәгемне салып ташладым,
рәхәтләнеп кырдым билчәннәрне,
күкбашларны, сарыбашларны.

Эшем бетте,
өстем тузанланды,—
эшләп булмый икән сакланып...
Арып-талып,
бакча уртасында
бер сәбәпсез торам шатланып...

Камил Мостафин.

?! **1.** Шигырьдәге хис сәбәпләрен әйтегез.

2. Лирик герой үзе, сәбәпсез шатлык була алмый, ди. Үзе шатлыгының сәбәбе юк ди. Лирик герой алдыймы? Шаяртамы? Аңламыймы? Бу сорауга дөрес җавап бирсәгез, авторның безнең белән сөйләшкән урынын таба аласыз.

БОЛЫТ.

Бер йомгак кебек булып
Тәгәрәп чыкты болыт.

Башта бик нәни иде,
Җил аны назлап сөйде.

Үчти-үчти иттерде.
Сөя-сөя үстерде.

Менә аякка басты,
Офыкларга тоташты.

Ай үсәсен көн үсте,
Түгә-түгә күз яшен.

Болыт кына булсаң да
Үсү авыр, күрәсең.

Мөдәррис Әгъләмов.

?! 1. Болыт хәсрәтенең зурлыгын ничек беләбез?

2. Болыт хәсрәтенең сәбәбен әйтегез.

3. Болыт белән җилне автор кемнәргә охшата?

4. Автор, ни өчен үсү авыр, ди? Ул шаяртамы, чынлап әйтәме? Әллә, безгә табарга кушып, төп фикерен әйтми калдырамы?

Истә калдырыйк. «Болыт» шигырен автор икешәр юлга бүлгән. Күп очракта шигырь дүртәр юлга бүленә. Әнә шул икешәр, дүртәр юлның һәркайсы **строфа** була.

«Абый булдым» шигырендә строфасын автор дүртәр юл иткән.

АБЫЙ БУЛДЫМ.

Йөри идем мин үземне
Белми кая куярга,
Минем хәзер сеңлем дә бар
Рәхәтләнеп уйнарга.

Рәхмәт аңа: ул тугач, мин
Абый булдым бер көндә.
Бәләкәй дип әйтә алмас
Мине хәзер беркем дә.

Хәкимҗан Халиков.

?! Малай хисенең ике сәбәбе бар. Шуларны әйтегез.

ШАТЛЫК.

Ильяс мәктәптән кайта. Ишектән керү белән, әтисенә:

— Әти! Мин бүген «биш»ле алдым. «Дүрт»ле берәү генә, ике генә «өч»лем бар! — ди.

?! Ильяс нигә шатлана?

УРАМЫБЫЗ ТУЗАНЫ.

Бу инде безнең урам,
Урам башында торам.
Бабам илне сакларга
Кузгалган менә моннан.

Мин бабамны күрмәдем,
Беләм утка кергәнен.
Нәкъ минем йөрүем, диләр,
Аның атлап йөргәнен.

Менә бу безнең урам.
Уртасында ук торам.
Әтием урман, болынга
Ияртә мине моннан.

Карап йөрдек урманын,
Айкап болын, кырларын.
Шулкадәрле рәхәт ул
Иркендә булуларың.

Тик сагындырды урам,
Урам башында торам.
Урман матур,
Болын матур,
Тик аларда юк тузан!

Тузан сагынган мине,
Килеп йөзгә бәрелде.
Китеп торсаң, урамыңның
Тузаны да кадерле.

Мөдәррис Әгъләмов.

?! Ни өчен авторга үзе яшәгән урамның тузаны да кадерле?

АВЫЛЫМ КИЧЕ.

Яшь бәбкә үләннәренә
Зәңгәр дым кунды.
Казлар кайтты су буеннан,
Тавыклар тынды.

Шундый тынлык тирә-якта:
Этләр дә өрми.
Әтәчләр дә тавыш бирми,
Песи дә йөрми.

Серле бер ләззәткә күмеп
Авылым кичен,
Күтәрелә дымсу җирдән
Җылы сөт исе...

Җылы сөт, яшь печән исе
Кушылып бергә,
Гомергә җуелмас булып
Сеңгән күңелгә...

Резеда Вәлиева.

?! **1.** Автор туган авылының кичке матурлыгын сагына. Аның өчен авылның кичке матурлыгы: үләндәге дым, тынлык, җылы сөт исе, печән исе.

Автор үзе кайда: авылдамы, шәһәрдәме?

2. Авылда яшәсәгез авыл кичен, шәһәрдә яшәсәгез шәһәр кичен яки таңын күз алдына китереп языгыз. Сез кичләрне ничек хәтерлисез?

ГӨЛКӘЙ.

Кайчандыр ир белән хатын яшәгән. Аларның балалары булмаган.

Көннәрдән бер көнне хатыны авыр сулап куйган да:

— Ичмасам, тәрәзә төбемдәге чүлмәктә гөл үсеп утырсын иде. Үз балам итеп тәрбияләр идем, — дигән.

Артына әйләнеп караса — тәрәзә төбендәге чүлмәктә бик матур гөл үсеп утыра.

Еллар үткән, гөл үскән, гөл белән бергә чүлмәге дә зурайган. Чүлмәк, зурая-зурая, казаннан да узып киткән, ә гөл чикләвек куагы белән тиңләшерлек булып үскән.

Беркөнне бу якларга шаһзадә килеп чыккан. Болар өе яныннан да узган. Егетнең тәрәзәдәге чүлмәкле гөлгә күзе төшкән. Гөлне ул бик ошаткан. Тәрәзә шакыган.

Хатын, тәрәзәсен ачкач: «Гөлегезне сатыгыз, күпме сорасагыз, шулхәтле акча бирәм», — дип ялынган.

Хатын гөлне кызганган, ләкин шаһзадә мең флорин акча сузгач, баш тарта алмаган. Яраткан гөлен сатып җибәргән. Егет чүлмәкне үз бүлмәсендәге тәрәзә төбенә куйган да гөленә иртә-кич су сипкән.

Шаһзадә берьялгызы ашарга ярата икән. Гөлне алып кайткан көнне дә үзе генә утырып ашаган. Гөленә сокланып утырган-утырган да йокларга яткан.

Егет күзләрен йому белән, гөл эченнән күзнең явын алырлык чибәр кыз сикереп төшкән. Кыз өстәлдәге сыйлардан бераз авыз иткән. Егетнең аяк очындагы лампаны баш очына, баш очындагы шәмнәрне аягы очына күчергән.

Иртән уянгач, бүлмәсендәге үзгәрешне күреп, шаһзадә хәйран калган. Бүлмә ишегенең биктә булуын белгәч, ни уйларга да белмәгән. Икенче көнне дә шул ук хәл кабатлангач, шаһзадә йоклаган булып яткан. Бераздан ни күзе белән күрсен — гөл эченнән дөньяда тиңе булмаган чибәр кыз сикереп төшкән. Кыз өстәлдәге ризыклардан авыз иткән, яктырткычларның урыннарын алыштыра башлаган. Баш очындагы шәмнәргә кулын сузуы булган, егет аның кулын тотып алган.

— Кемнән куркасың, нигә качасың, чибәркәй? — дип сораган шаһзадә.

— Мине күрдең, димәк, мин синеке хәзер. Ләкин, кара аны, мине күрүеңне берәүгә дә сөйләмә, — дип кисәткән кыз.

— Килештек. Берәүгә дә бер генә сүз дә ычкындырмам, — дип ышандырган шаһзадә һәм ялчыларына моннан соң ашны ике кешелек итеп китерергә кушкан.

Берничә ай үткән. Егет әтисе белән сугышка китәргә тиеш булган. Китәр алдыннан, әнисен бик нык кисәткән: гөлгә иртә-кич су сип, көн дә, иң затлы ашамлыклар кертеп, бер кешелек табын әзерлә, бүлмә ишеген биктә тот, дигән. Ә гөл-кызын, мине юксынма, тиздән әйләнеп кайтырмын, дип юаткан.

Әйтергә кирәк, шаһзадәгә вәзир кызын ярәшкән булганнар. Гөл чүлмәгендәге кызны күргәннән соң, ул ярәшкән кызын бөтенләй оныткан. Очрашмаган, сөйләшмәгән, әйтерсең лә ул бөтенләй булмаган.

Вәзир кызы ни уйларга да белмәгән. Шаһзадәнең сугышка китүен ишеткәч, ул әнисе белән патша йортына килгән. Үзгәрешнең сәбәбен белү өчен, патша хатынының кылын тартып карарга булганнар. Бераз сөйләшеп утырганнан соң, патша сараен карап йөргәннәр. Шаһзадә бүлмәсе янына килеп җиткәннәр. Вәзир хатыны кызына күз кыскан да патша хатынына:

— Булачак кияү бүлмәсен күз кырые белән генә булса да карар идек, күрсәтмәссеңме? — дип үтенгән.

Патша хатыны бүлмә ишеген ачкан. Бүлмә эченә вәзир кызының кереп китүен күрми дә калган. Гөлкәйнең, тәрәзәдән диңгезгә карап, чәчен тараган чагы икән. Алтын тарагыннан суга коелган чәчләре, шунда ук алтын балыкка әйләнеп, йөзеп китәләр икән.

Вәзир кызы кияү егетенең нигә югалуын шунда ук аңлап алган.

«Имәндә икән чикләвек! Кияү буласы егетемнең күзе башка кызга төшкән икән»,— дигән. Вәзир кызы күз ачып йомганчы тәрәзә янына йөгереп килгән. Аның гөл-кызын диңгезгә төртеп төшерүен берәү дә күрми калган.

Ләкин гүзәл кыз су өстенә йөзеп чыга алган. Кояшның җир читенә төшеп барган чагы икән. Кояш алтын нурлары белән кызны кочаклап алган да әнисе йортына алып кайткан.

Шаһзадәнең әнисе, гөлгә су сибәргә дип, бүлмәгә керә. Ни күзе белән күрсен — улы күз карасы кебек сакларга үтенгән гөл шиңгән. Ә кичен кереп караганда инде тәмам корыган булган. Өстәлдәге ризыкка да кагылучы булмаган.

Ул арада Шаһзадә сугыштан кайтып төшкән. Бүлмәсенә кергәч күрә: гөле шиңгән, корыган. Егет озак елаган. Әнисенә елый-елый:

— Нигә су сипмәдең, әни? Шиңдереп харап иткәнсең! — дип, үпкәсен белдергән.

— Сиптем, улым. Вакытында сиптем. Нигә шиңгәнен үзем дә башыма сыйдыра алмыйм, — дип акланган әнисе.

— Бүлмәгә ят кеше кермәгәндер бит?

— Ант итеп әйтәм: ятлардан берәү дә кермәде. Әнисе белән булачак кәләшең генә кереп караганнар иде, — дигән әнисе.

Шаһзадә фаҗигането сәбәбен шунда ук аңлаган. Хәсрәтеннән авырып, аяктан егылган. Хәлен белергә вәзир кызы кергәч, аны куып чыгарган.

Ә бөтен дөньяда тиңе булмаган кыз Кояш йортында яши биргән. Кояштан: «Шаһзадә сугыштан кайтмадымы, хәле ничек?» — дип сораштырып торган.

— Юк, кайтмады әле, сабыр бул, — дип җавап бирә торган булган Кояш. Ләкин беркөнне бүтәнчә әйткән:

— Кайтты шаһзадәң, ләкин авырып ята. Иң оста табиблар да чирен белә алмыйлар. Ашамый, эчми,

корыган гөлгә карап ята да ята. Озак яшәмәс инде, — дигән.

— Кояшым, бәгърем, үтенеп сорыйм, иртәгә дөньяны яктыртырга чыкканда, мине дә үзең белән алсаңчы. Шаһзадә тәрәзәсен яктыртырсың, бер нурыңны гөл чүлмәгенә төшерерсең. Мин шул нур өстеннән йөгереп китәрмен дә чүлмәгемә сикерермен,— дип ялварган.

Кояш кыз гозерен үтәгән. Нурын туп-туры чүлмәк төбенә төшергән. Кыз нур өстеннән йөгереп килгән дә, гөл эченә кергән. Гөл яфраклары шунда ук күтәрелгәннәр, яшелләнгәннәр. Гөл чәчәк аткан. Ә чәчәк элеккесеннән дә гүзәлрәк булган. Шаһзадә, гөленең терелүен күрү белән, чирен оныткан. Ятагыннан торып шатланган, көлгән. Түземсезлек белән кичне көткән.

Менә көткән кич тә килеп җиткән. Сарай кызлары өстәлне затлы ризык белән тутырганнар. Егет ишегең бикләгән. Гөл эченнән чибәрлеге белән бөтен дөньяда тиңе булмаган кыз егет каршына килеп утырган. Алар төне буе сөйләшеп чыкканнар.

Төн тиз үткән. Кояш чыккач, шаһзадә туй буласын хәбәр иткән. Үзенең сөйгәне белән ул күп еллар иң бәхетле кеше булып яшәгән. Ә вәзирнең усал кызы белән усал хатынын шәһәрдән кудырган.

?! 1. Әкиятне хәтердә калдырып сөйләр өчен әзерләнегез, вакыйгаларга бүлегез. Мәсәлән:

а) Шаһзаданең чүлмәктәге гөлгә гашыйк булуы турындагы вакыйга... (Дәвам итегез.)

ә) Үзегез белгән вакыйгалар турында сөйләгез.

2. Шаһзадә хисләре үзгәреп тора. Ничек үзгәрә? Сәбәпләрен әйтеп аңлатыгыз.

3. Әкияттә тагын кайсы персонажның хис-кичерешләре бар. Аңлатып сөйләгез.

ШЫГЫРДАВЫКЛЫ БАШМАКЛАР.

Гөлшатның сары башмаклары бар. Сап-сары, сары күбәләк канаты төсле башмаклар. Их, матурлар да! Үзләре тагы аякка кию белән җырлый башлыйлар: шыгыр-шыгыр, шыгыр-шыгыр. Әйтерсең олтаннарында тылсымлы кубыз бар.

Мондый башмакларны киеп, урам ташларын текелдәтеп, тек-тек итеп басып йөрүең ни тора!

Бөтен балалар Гөлшатның аягына карыйлар. Балалар гынамы соң? Талда чутылдашып утырган чыпчык малайларына кадәр башларын кыйшайталар да елтыр күзләрен сары башмакларга төбиләр.

Бик-бик кадерле бүләк алар. Әтисе Гөлшатка Мәскәүдән җибәргән ул сары башмакларны. Ә аның әтисе — танкист. Гөлшат аларны, киеп, беренче көнне үк Ләләгә күрсәтте. Ничек күрсәтмәсен, Ләлә — Гөлшатның иң якын дусты ич. Күрше бүлмәдә генә тора. Алар икесе бергә бакчага баралар. Шулай бергәләшеп кайталар да. Кайткач, курчаклы уйныйлар.

Ләләнең дә әтисе фронтта. Исән генә булсын. Әтисе, кайткач, Ләләгә дә шыгырдавыклы башмаклар алып бирер әле.

?! Хикәянең баш өлеше башмаклар турында. Бу өлештә Гөлшат хисе дә бар. Нинди хис?

Ә менә Гөлшатның әтисе кайтты да инде. Әтисе белән бергә бәйләм-бәйләм, кочак-кочак бәхет нурлары кайтты. Ул кайткач, өй эче дә бөтенләй яктырып китте сыман. Әллә әтисенең күкрәгендәге йолдызлар шулай балкыттылар инде өйне, әллә кояш юмартланыбрак көлә башлады.

Гөлшатның башмаклары дисәң, алар тагын да күңеллерәк шыгырдыйлар. Менә бит ул ничек — әти кайткач!

Гөлшат, сөенеченнән нишләргә белмичә, Ләләләргә йөгереп керде.

— Әтием кайтты! Их! Йолдызлары ла йолдызлары! — дип кычкырып җибәрде ул.

Тик аңа эндәшүче булмады.

Ләләнең әнисе сандык өстендә елап утыра. Ләлә дә әнисенә кушылып, үкси-үкси елый иде.

Ул, башын күтәреп, калтыравыклы тавыш белән:

— Хәзер инде минем сары башмакларым булмас, — диде.

— Әйе, күгәрченем, әтиеңнең батыр гәүдәсе сугыш кырларында ятып калды. Кабере өстенә миләүшәләр үскәндер инде, — диде әнисе, авыр сулап, һәм, кызын кочаклап, тагын елый башлады.

Гөлшатның күкрәгенә таш кереп урнашкандай булды.

?! Хикәянең әле генә укыган өлешендә башка персонажлар хисе турында сөйләгез.

Шул вакытта ишек ачылып китте дә, өйгә Ләләнең өч иптәш кызы килеп керде. Берсе мәк чәчәге төсле кызыл туп тоткан. Икенчесе зур курчак күтәргән. Өченчесенең кулында чәчәк бәйләме.

Кызлар Ләлә янына килделәр.

— Бу тупны идәнгә бәрсәң, ул түшәмгә кадәр сикерә, — диде бер кыз һәм тубын елап утырган иптәшенә бирде.

— Бу курчагымның күзләре ачыла да, йомыла да белә. Ул мине бик ярата. Ал, Ләлә, курчагымны. Ул сине дә шулай яратыр, — диде икенче кыз.

— Бу чәчәкләремне үзем сайлап алдым, — диде өченчесе. Хуш исле чәчәкләрен Ләләгә сузды.

Тагын ишек ачылды. Бу юлы Гөлшатның әтисе килеп керде. Керде дә Ләләне кулына күтәреп алды.

— Иһи! — диде ул, аның кулыннан тубын алып. Тупны идәнгә бер бәрде, туп идәнгә кадәр сикерде.

— Ләлә кызым! Мин сине иртәгә курчак театрына алып барырмын, Гөлшат та барыр. Барырсың бит, Гөлшат?

Гөлшат бер сүз дә әйтмәде. Тиз генә чыгып китте дә бүлмәсенә кереп актарынырга тотынды.

— Кызым, ни эзлисең анда? — дип сорады әнисе.

— Берни дә түгел, — диде Гөлшат. Ә үзе һаман эзләнә. Әйберләрнең берсен ала, берсен куя.

Менә аның күзләре сары башмакларына төште. Башмакларын кулына алды да әйләндерә-әйләндерә карады. Нинди чибәрләр бит! Менә ул аларны күкрәгенә кысты. Тагы бераз әйләндергәләп торды. Шуннан соң әнисе янына килде.

— Әнием! Ләләгә кызлар чәчәкләр алып килделәр. Аннары курчак та, аннары тагы туп. Мин дә башмакларымны бирәм, әнием, яме?

— Ярый, ярый, акыллым. Бик яхшы булыр, сөендер иптәшеңне. Бар, бүләгеңне кертеп бир, — диде әнисе.

Гөлшат кергәндә, Ләләнең әнисе еламый иде инде. Ул кызын юатып, әллә ниләр сөйләп утыра иде.

Гөлшат иптәше янына ук барырга кыймады. Бераздан тирән, бик тирән итеп сулап куйды да:

— Ләлә! Мә, башмакларымны киеп кара, аягыңа сыямы? — диеп, Ләләгә аларны кияргә дә булышты.

Ләлә, аякларына иелеп карый-карый, ишекле-түрле йөри башлады.

— Сап-сары, сары күбәләк канаты төсле бит үзләре! — диде Гөлшат, дусты тирәсендә сикергәләп. — Дускаем! Мин сиңа аларны бүләк итәм. Теләсәң ничек шыгырдатып йөр, яме!

Кинәт Гөлшатка бик җиңел, бик рәхәт булып китте.

Дәрҗия Аппакова.

?! Соңгы өлешкә исем бирегез.

1. Мәктәпкә ашыга-ашыга барганда, ташка абынып, аягыгызны авырттырдыгыз, ди. Аяк авыртуның сәбәбе — егылу. Егылу сәбәбен языгыз.

2. Аяк авырту хисме?

3. Үкенү — хис. Үкенү хисенә сәбәп уйлап табыгыз.

КАЮЛЫ ЧИТЕК.

Әти алган бүләк итеп
Миңа каюлы читек.
Сабантуйда күрсәтермен,
Тыпырдап биеп китеп.

Бер адым атлаган саен,
Шыгыр-шыгыр итә ул.
Тик кузгатып кына җибәр,
Үзе биеп китә ул.

Мәрзия Фәйзуллина.

1. Бүләк алган кыз ни өчен читеген бии ди? Алдыймы? Шаярамы? Мактанамы? Шатланамы?

2. Бүләк алучы кызга ышаныйк та, читекне биеп китте дип, күз алдына китерик. Читекнең ничек биюе турында языгыз.

ОТЛИЧНИК.

Ур-ра! Мин «биш»ле алдым!
Ничек итеп алганымны
Үзем дә сизми калдым.
Бер сәгатькә булса да,
Бер дәрестә булса да,
Отличник булып алдым!

Роберт Миңнуллин.

1. Бу шигырьнең лирик герое өченче сыйныфта укучы малай дип уйлыйк. Шул малай шатлыгының сәбәбен һәм дәрәҗәсен әйтегез.

2. Малайга бәя бирегез. Ул нинди укучы?

АВЫРЫП ЯТКАНДА.

Мәктәпкә дә баралмыйм,
Урыннан да торалмыйм.

Чынаяк та тоталмыйм,
Хәтта дару йоталмыйм.

Карлыккан тавышым да,
Чатный гына башым да.

Китап та укый алмыйм —
Хәлләремне бик аңлыйм...

Малайлар — урамдадыр,
Туйганчы уйныйлардыр,

Аларны тыймыйлардыр,
Чыгармый тормыйлардыр...

Их, әни тыймасамы?
Урамда уйнасаммы? —

Мин дә терелер идем,
Аз гына уйнасам да,
Терелеп керер идем.

Тик әни чыгарырга
Бөтенләй уйламый да.

Терелермен әле бер
Урамда уйнамый да!

Роберт Миңнуллин.

?! 1. Әсәрнең лирик шигырь булуын исбат итегез.
2. Лирик герой хисенең сәбәбен әйтегез.

УМЫРЗАЯ.

Кар астыннан чыгып басты,
Әкрен генә күзен ачты.
— Аһ, соңладым, ахры, — диде,
Авыр сулап башын иде.

Озын керфекләрен сирпеп
Карады да матур итеп,
Шундый назлы итеп көлде,
Тирә-якка нур бөркелде.

Чыпчыклар да, каргалар да
Куандылар шулчак бар да:
— Безнең зарыкканны белгән,
Яздан хәбәр алып килгән!

Урман әле яп-ялангач,
Яфрак ябынмаган агач,
Карлар җемелдәшеп ята,
Ә умырзая чәчәк ата!

Резеда Вәлиева.

?! **1.** Хисле катнашучыларны әйтеп чыгыгыз.
2. Лирик геройны табыгыз.

КЫШКЫ КИЧ.

Кызык сезгә, яшь балалар, кышкы кичтә!
Җылы өйдә утырасыз якын мичкә;
Утырасыз рәхәтләнеп, тезелешеп,—
Шатлык сезгә, уңайсызлык килми һич тә.

Һичкайсыгыз таныш түгел хәсрәт берлә,
Утыргансыз матур гына, рәт-рәт берлә;
Кышкы кичнең озынлыгын сизмисез дә,
Әнкәгезнең сөйләгәне әкият берлә.

Тышта иссен ачы җилләр, тузсын карлар,
Өй түбәсе саламнары килсен тар-мар,
Суыклыктан очар кошлар очалмасын,—
Сезнең урын җылы, әйбәт,— ни кайгы бар?

Төшсен ләкин исегезгә кайсы вакыт:
Һәркемгә дә бирелмәгән мондый бәхет;
Ятим калган сабыйлар бар, бәхетсезләр,
Ата-анасы вафат, җирсез һәм йортсызлар.

Мондый кышкы кичтә сыгъныр[1] урыннары
Аларның юк, өши бите, борыннары;
Үлми калса яхшы алар салкынлыктан,
Кайберсенең шуннан була үлемнәре.

Очрый калса сезгә шушындый ярлылар,
Яшьле күзле, моңланганнар вә зарлылар,—
Яшь балалар! Аларны сез яратыгыз,
Җылы сүзләр әйтеп, сөеп юатыгыз!

Габдулла Тукай.

?! 1. Шигырьне ике өлешкә бүлегез.
2. Лирик геройның хисе турында сөйләгез.

ҖЫРЛЫЙМ ӘНИЕМ ТУРЫНДА.

Бер кыз бала җыр чыгарган,
Багышлап әнисенә.
Икәү бергә җырлыйк диеп
Өйрәткән энесенә:

---

[1] Сыгъныр — сыеныр.

Кояш, кояш
Мәңге балкый,
Мәңге нур сибә.
Кояш гомере телим мин,
Әнием, сиңа!

Җырны чишмәләр ишеткән,
Кошлар отып алганнар.
Сандугачлар һәм тургайлар
Матур көйгә салганнар:

Кояш, кояш
Мәңге балкый,
Мәңге нур сибә.
Кояш гомере телим мин,
Әнием, сиңа!

Кушыл син дә, җырлыйк бергә,
Яңа матур җыр тусын.
Җирдә әниләр кояштай
Озын гомерле булсын:

Кояш, кояш
Мәңге балкый,
Мәңге нур сибә.
Кояш гомере телим мин,
Әнием, сиңа!

Гөлшат Зәйнашева.

?! Беренче строфа яңа җыр иҗат итү турында. Шуңа күрә аңа «Яңа җыр» дип исем кушыйк. Әсәрнең икенче өлешен табыгыз. Тагын ничә өлешкә бүлә аласыз?

БӨЕК СӘЯХӘТЧЕЛӘР.

Алты яшем тулганда, мин Җир шарының шар кебек түгәрәк булуын белми идем әле. Ләкин без ял итә торган дача хуҗасының улы Стёпка Җирнең нинди булуын аңлатып бирде.

—Җир тәгәрмәч кебек ул, туп-туры китсәң, аны әйләнеп чыгу берни түгел. Барасың, барасың да кабат үз өеңә килеп чыгасың,— диде.

Ышанмыйм, дигәч, Стёпка муен төбемә берне кундырды да:

—Алай-болай сәяхәткә китә калсам, сине ияртмим. Сине алганчы, сеңлеңне алу хәерлерәк. Синеңише тиле белән Җирне әйләнеп чыгуның миңа ни кызыгы бар? — диде.

Ләкин минем сәяхәткә барасым килде. Мине дә иярт дип, Стёпкага пәкемне бүләк иттем. Аңа пәке ошады, шуңа күрә сәяхәткә мине дә алырга риза булды.

Бәрәңге бакчасында Стёпка сәяхәтчеләрнең гомуми җыелышын үткәрде. Анда ул миңа һәм Лёляга:

—Иртәгә әти-әниегез шәһәргә киткәч, ә минем әни елгага кер чайкарга төшкәч, юлга чыгабыз. Туп-туры китәчәкбез. Таулар, чүлләр кичәчәкбез. Өйгә кире әйләнеп кайтканчы турыга барачакбыз. Бер ел үтсә үтәр, ләкин шушында әйләнеп кайтачакбыз,— диде.

—Ә индеецлар очраса нишләрбез? — дип сорады Лёля.

— Индеецлар мәсьәләсенә килгәндә, без аларның бөтенесен әсирлеккә алачакбыз,— дип җавап бирде Стёпка.

Стёпка сарайдан он капчыгы алып чыкты. Капчыкка ипи белән шикәр, аннан соң тәлинкә, стаканнар,

кашыклар салдык. Бераз уйлап торгач, аларга фонарь, буяу карандашлары, кул юу өчен балчык савыт, учак яндырып җибәрү өчен дип, зурайтып күрсәтә торган пыяла өстәдек. Ә иң өскә ике юрган белән бер мендәр куйдык.

Шулардан тыш, мин үземә өч рогатка, балык тоту өчен озын чыбыклар, ә Африкада күбәләк аулар өчен, кечкенә генә булса да ятьмә әзерләп куйдым.

Икенче көнне әти белән әни өйдә юкта, ә Стёпканың әнисе елга буена төшеп киткәч, авылдан чыгып киттек.

Иң алдан Стёпканың эте Тузик элдертә. Эте артыннан, зур капчыкны иңбашына күтәреп, Стёпка атлый, аның артыннан, сикергеч аша сикерә-сикерә, Лёля бара, алар артыннан, өч рогаткамны, ятьмәмне һәм чыбыкларымны тотып, мин барам.

Шактый вакыт үткәч, Стёпка:

— Капчык бик авыр, чиратлашып күтәрик, — диде.

Лёля бик тиз арыды, капчыгын ташлады да:

— Минька күтәрсен, — диде.

Капчыкны җилкәмә салгач, аның авырлыгына ах иттем. Шунда ук бөгелеп төштем. Уңга-сулга чайкалып, ун адым киттем микән, капчыгым-нием белән канауга аудым.

Савыт-саба ватыкларын капчык эченнән алып ташлагач, Стёпка минем муен төбенә берне кундырды да:

— Синең ишеләргәме соң Җир әйләнә сәяхәткә чыгу! — диде.

Бераздан капчыкны өчебез өч яктан тотып киттек. Ул үзе авыр, җитмәсә, тотарга уңайсыз иде. Алай да ике сәгать бара алдык. Аннан соң, урманны үтеп, яланга чыктык. Ял итәргә утырдык.

— Шушында кунабыз, — диде Стёпка.— Йоклаганда мин аякларымны барасы юнәлешкә таба сузып ятармын. Бөек сәяхәтчеләрнең барысы да, адашмас өчен, шулай йоклаганнар, — дип тә өстәде.

Капчыктан ипи белән шикәр алып, ашарга утырдык. Өстенә шикәр комы сибелгән ипине бер-ике кабарга

өлгердек микән, безне шөпшә сырып алды. Берсе минем битне чагарга да өлгерде.

Яңак бәлеш хәтле булып шеште. Минем өйгә кайтасым килә башлады...

— Кем өйгә кайтасы килә дип шыңшый, шуны агачка бәйләп куям да шушында калдырам, — дип кисәтте Стёпка.

Кузгалыр алдыннан, ул капчыктагы нәрсәләрнең барысын да диярлек чыгарып ташлады, шуннан соң йөгебез шактый җиңеләйде.

Мин, шешкән яңак авыртуыннан ыңгыраша-ыңгыраша, иң арттан барам.

Лёля да бу сәяхәттән тәмам туйган иде. Ул да өйгә кайту турында сөйләнә башлады.

Бара торгач караңгыланды. Стёпка капчыгын җиргә ташлады да зурайтып күрсәтә торган пыяласын алды. Без, учак ягар өчен, коры-сары җыеп китердек.

Ләкин, куктән кояшны таба алмагач, Стёпка күңелсезләнде. Безнең дә кәеф бозылды. Ипи генә ашап, йокларга яттык.

Иртәгә кайсы якка барасы билгеле булсын дип, Стёпка аякларын алга таба сузып ятты...

Михаил Зощенко.

?! Сәяхәтчеләребез, әлбәттә, әйләнеп өйләренә кайталар. Ни өчен кайталар? Стёпка кайтырга теләми бит.

УЛ ҮСКӘНДӘ.

Кеп-кечкенә булып туган иде,
Хәзер сизәм көн дә артуын.
Күргән саен шуны, йөрәгемдә
Дулкынланып таша шатлыгым.

Кайчагында йокы арасында
Ыңгыраша әрнеп кечкенәм!
Мин калтырап китәм, бозлы яңгыр
Койган төсле була өстемә.

Аның өчен күргән авырлыклар,
Читенлекләр бер дә сизелми.
Кырык чирне алып үз өстемә,
Аны саклап калыр идем мин.
Ул елмайган чакта, көн аязып,
Кояш чыккан төсле тоела.
Арткан саен аның бер «һөнәре»,
Шатлык белән күңел коена.

Бүген әле менә беренче кат
Аягына тәпи басты ул.
Күккә тиде түбәм, әйтерсең лә
Минем өчен котып ачты[1] ул!
Мин сокланып карыйм күзләренә,
Күзләрендә куе зәңгәрлек.
Мин күзәтәм гүя зур диңгездә
Бик кыйммәтле яшерен җәүһәрне.
Сакта төсле сизәм мин үземне
Шул кыйммәтле җәүһәр янында.

Муса Җәлил.

?! **1.** Беренче строфаны кабат укып чыгыгыз. Анда лирик геройның шатлык һәм борчылу хисләре турында әйтелә. Шул ике хиснең сәбәпләре турында сөйләгез.

2. Икенче строфада хис турында языламы?

3. Өченче строфада әтисенең кызына мәхәббәте ничек сурәтләнә?

---

[1] Котып ачты — яңа денья ачты.

Ятлау өчен.

ИҢ БЕРЕНЧЕ СҮЗ.

Бер сүз дә булмаган чакта,
Кем сүз уйлап чыгарган,
Ничек бик тә дөрес итеп
Исемнәр кушып барган?

Ничек «бүре» димәгән ул
«Куян» дигән куянга
(Чыгарлар иде куяннар
Бүреләрне куарга!)?

Алманы «алма» дигән бит,
«Суган» диеп куймаган
(Башта ашап карагандыр,
Ә аннары уйлаган)...

Ә иң-иң-иң-иң беренче
Әйтте микән ни диеп?
Ашыйсы килеп уянгач
Дәшкәндер: «Әни!» — диеп...

Шәукәт Галиев.

Шаянлыкка, иҗади хәйләгә килгәндә, Шәукәт Галиевкә җиткән әдип күренми әле. Шагыйрьнең шаянлык

серләрен әсәрләренә анализ ясый-ясый өйрәнсәгез, бәлки, аның кебек, ә бәлки, аңардан да остарак үткен фикерле әдип булырсыз! Балаларны көлдереп тә, яраттырып та, шул ук вакытта уйлатып та, сагышка батырып та яшәргә өйрәтерлек әдипләр булсагызмы? И шатланыр иде дә соң Шәүкәт абыегыз. Сез аны иңиң бәхетле шагыйрь итәр идегез.

Ятларга тиешле шигыренә генә күз салыгыз. Шагыйрь борынгы бабайларны мактый. Алар бүрегә «бүре», куянга «куян», суганга «суган» дип исем биргәннәр, ди. Үзе безгә каш астыннан гына карап елмая: «бүре» сүзендә бүре юк, «куян» сүзендә дә куян юк. Шаяртуымны аңлыйсыз бит, ди.

Шагыйрь борынгы бабайларны бик җитди итеп мактый һәм нәни баланың әнисенә «әни» дип әйтүен «әйтте микән?» дип шик астына куя. Без, шагыйрьнең чын сүзенә ышанмыйча, шаярта, дибез. Ә «әни» сүзен кеп-кечкенә бала әйтте микән дип шикләнсә дә, аның бу сүзләренә ышанабыз. Әниләргә «әни» дип беренче мәртәбә үз баласы әйтә. Барыбызның да беренче сүзе «әни» булды бит. Шәүкәт Галиев безнең шулай уйлавыбызны һәм бу шигырьне укыганда барыбызның да үз әниебезне күз алдына китерүебезне яхшы белгән.

ТАҢ.

Зәңгәр яулык япкан иртә
Йокысыннан уянды.
Ул күзләрен ачу белән,
Алланып, офык янды.

Һәм ул күрде шаян җилнең
Агачны уятканын,
Тулган айның тау артында
Югалганын, батканын.

Аннан күрде юынганын
Чык белән үләннәрнең
Һәм ишетте чәчәкләрнең
Чылтырап көлгәннәрен...

...Таң күргәнен, бөтенесен
Үз күзем белән күрдем,—
Чөнки бүген, иртүк торып,
Болында уйнап йөрдем.

Разил Вәлиев.

Баштагы ике юл бик матур шигырь теле белән язылган. Таң ата башлады, дияр идек без, күккә карап. Автор таңны башта күз алдына берничек тә китереп булмый торган кешегә охшата. Караңгы күк ачыла башлады, дими, иртә зәңгәр яулык япты, ди. Офыкта кояш нурлары күренә башлады, дими, таң күзен ачты, шуның өчен офык кып-кызыл төскә керде, ди.

Нибары кып-кыска дүрт юл. Шул юлларның эчтәлеген ачар өчен, әнә күпме җөмлә кирәк булды. Шундый бай эчтәлекле юлларга автор уйлап тапкан **сурәт** яисә **сәнгать теле** диләр. Лирик геройның таң ату матурлыгына соклануын шагыйрьләр сөйләп бирмиләр, әнә шулай сәнгать теле аша сурәтлиләр.

Сез дә, калган дүртьюллыклар арасыннан үзегез теләгәннәрен сайлап, эчтәлекләрен үз сүзләрегез белән дәфтәрләрегезгә языгыз.

КЫШ КӨНЕНДӘ ҖӘЙ ИСЕ.

...Өстәлдәге чәчәкләрдән
кыр исе килеп тора;
иснәгән саен иснисе,
карыйсы килеп тора.

...Чәчәк-чәчәк чәкчәкләрдән
бал исе килеп тора;
сине, чәкчәк, алып чак-чак,
ялыйсы килеп тора...

...Ятлаган шигырьләремне
сөйлисе килеп тора;
мактасалар, кул чапсалар
биисе килеп тора.

Әйе, бездә,
өебездә
алма исе, бал исе,
мәтрүшкәле чәй исе, —
әнкәйнең туган көнендә
кыш көне дә җәй исе!

Мәхмүт Газизов.

?! Өстәлдәге чәчәкләрдән ни өчен кыш көне дә җәйге кыр исе килә?

Эчтәлек

Беренче һәм икенче сыйныфларда өйрәнгәннәрне искә төшерү.

Безнең гаилә. *Габдулла Тукай* 3
Без ничәү? *Хәкимҗан Халиков* 3
Төзәтәм. *Нурия Измайлова* 4
Васыять. *(Мәзәк.)* 5
Эш һәм ял. *Әхмәт Исхак* 6
Яшьләр колагына. *Клара Булатова* 8
Яз. *Рөстәм Мингалим* 9
Яз. *Нәҗип Думави* 10
Кичке кояш. *Разил Вәлиев* 10
Кызык әкият. 11
Бәхет чикләвекләре. *(Болгар халык әкияте.)* 11
Юл. 15
Яшьлек чишмәсе. *Нури Арсланов* 15

Әсәрне өлешләргә таркату.

Чисталык яратабыз. *Мәрзия Фәйзуллина* 19
Ташбака илә Куян. *(Мәсәл.) Габдулла Тукай* 20
Ак күбәләк. *Фатих Кәрим* 20
Ай. *Рәшит Бәшәр* 21
Ишәк илә Сандугач. *(Мәсәл.) Габдулла Тукай* 22
Шаян җил. *Резеда Вәлиева* 23
Ашка үпкәләмә. *Нури Арсланов* 24
Өч гөлчәчәк. *(Татар халык әкияте.)* 25
Ике Салкын. *(Рус халык әкияте.)* 27
Иң зур кеше. *Рөстәм Мингалим* 28
Кайтыйк ла үзебезгә! *Роберт Миңнуллин* 29
Кәҗә белән кәбестә. *Шәйхи Маннур* 30

Аш ашка, урыны башка. *(Мәзәк.)* 31
Саран белән Юмарт. *(Татар халык әкияте.)* 32

Бөтенлек.

Наил аркасында. *Альберт Гатуф* 37
Югалганмы? *(Мәзәк.)* 38
Шәвәли сәгате. *Шәүкәт Галиев* 39
Җил нинди? *Лена Шагыйрьҗан* 39
Кичә генә. *Клара Булатова* 40
Андый булмагыз. *Клара Булатова* 41
Кыш һәм кеше. *Бари Рәхмәт* 41

Әсәрне охшаш өлешләрен кушып бүлү.

Чыршы. *Габдулла Тукай* 43
Кояшның нурлары. *Дәрдемәнд* 44
Үги кыз. *(Татар халык әкияте.)* 45
Кыш усаллыгы. *Константин Ушинский буенча* 48
Билгеле урын. *Йолдыз* 49
Шауламагыз, әти йоклый. *Шәүкәт Галиев* 51
Иң тәмле икмәк. *Салих Баттал* 52
Һөнәрле үлмәс. *(Татар халык әкияте.)* 54

Кеше сыйфатының дәрәҗәсен сурәтләү.

Ботка. *(Әкият.)* 60
Өч туган. *Бертуган Якоб һәм Вильгельм Гриммнар* 62
Чыдамады. *(Татар халык әкияте.)* 64
Куркак кеше. *(Татар халык әкияте.)* 66
Оста сунарчы. *(Мюнхгаузен истәлекләре.)* 66
Бүрек. *(Әрмән халык әкияте.)* 70
Җитезләр. *(Африка халкы әкияте.)* 70
Тими тел очына да. *Роберт Миңнуллин* 71
Гулливер сәяхәте. *Джонатан Свифт* 72
Җизни әкияте. *Шәүкәт Галиев* 80

Кешенең күңел дөньясы.

Хиснең дәрәҗәсе.

Мәктәпкә. *Зыя Мансур* 86

Сусыз елга. Рафаил Төхфәтуллин 86
Ак гөмбә. *Альберт Гатуф* 87
Безне сагынып. *Нурия Измайлова* 90
Сөбханалла! *Резеда Вәлиева* 91

Хиснең сәбәбе.

Эш. *Камил Мостафин* 92
Болыт. *Мөдәррис Әгъләмов* 93
Абый булдым. *Хәкимҗан Халиков* 94
Шатлык. *(Мәзәк.)* 95
Урамыбыз тузаны. *Мөдәррис Әгъләмов* 95
Авылым киче. *Резеда Вәлиева* 96
Гөлкәй. *(Грек халык әкияте.)* 97
Шыгырдавыклы башмаклар. *Дәрҗия Аппакова* 103
Каюлы читек. *Мәрзия Фәйзуллина* 106
Отличник. *Роберт Миңнуллин* 107
Авырып ятканда. *Роберт Миңнуллин* 107
Умырзая. *Резеда Вәлиева* 108
Кышкы кич. *Габдулла Тукай* 109
Җырлыйм әнием турында. *Гөлшат Зәйнашева* 110
Бөек сәяхәтчеләр. *Михаил Зощенко* 112
Ул үскәндә. *Муса Җәлил* 115

Ятлау өчен.

Иң беренче сүз. *Шәүкәт Галиев* 117
Таң. *Разил Вәлиев* 118
Кыш көнендә җәй исе. *Мәхмүт Газизов* 120

Учебное издание

Яхин Альберт Гатинович

ЛИТЕРАТУРА

Учебник для 3 класса
начальной общеобразовательной школы
с татарским языком обучения

В двух частях

Первая часть

Казань. Издательство «Магариф». 2010

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Яхин Альберт Гатинович

ӘДӘБИЯТ

Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең
3 нче сыйныфы өчен дәреслек

Ике кисәктә

Беренче кисәк

Редакторы *З. М. Гыйниятова*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *Н. А. Казакова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Э. Ф. Нурмехәмматова*
Корректоры *С. З. Гыймалетдинова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 11.05.2010.
Форматы 70 × 90 1/16. Офсет кәгазе. «Букварная» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 9,07 + форз. 0,29.
Нәшер-хисап табагы 5,21 + форз. 0,49.
Тиражы 3100 д. Заказ О-735.

«Мәгариф» нәшрияты. 420059. Казан, Оренбург тракты, 20а.
Тел./факс (843) 277-52-88; 277-52-62.
E-mail: magarif@mail.ru
http://www.magarif.com

«Татмедиа» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

ISBN 978-5-7761-2065-7